Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



3 класс

ФГОС

издательство
«Татармультфильм»





Мәктәп

**Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина**

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

**БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК**
**(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)**

**ДӘРЕСЛЕК Е.И. ПАССОВНЫҢ**
**КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ**

**КАЗАН**
**«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ**
**2025**

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я722
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Работа в группах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 3 класс: учебник для образовательных организаций начального общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. — Казань: Татармультфильм, 2025. — 128 с.: ил.

ISBN 978-5-906508-60-7

**ISBN 978-5-906508-60-7**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я722**

© Хайдарова Р.З., Ахметзянова Г.М., Гиниятуллина Л.А., 2025
© Оформление. Издательство «Татармультфильм», 2025
Все права защищены.






ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»

# мәктәптә

## 1–3 нче дәресләр

**1.** Внимательно рассмотри рисунок. Кого ты видишь? Как назовёшь рисунок?




**2.** Текстны укы. 1 нче сентябрь нинди көн?

Бүген яңа уку елы башлана. Укучылар мәктәпкә баралар. Мәктәптә Белем көне — 1 нче сентябрь. Күңелле музыка уйный. Мәктәптә күңелле.

**Белем көне** — День знаний
**яңа уку елы** — новый учебный год
**башлана** — начинается

**3.** Сорауларга җавап бир.

1) Укучылар кая баралар?
2) Мәктәптә нинди бәйрәм була?
3) Ни өчен мәктәптә күңелле?

**4.** Составь диалог по вопросам упражнения 3 и поговори с соседом по парте.

**5.** Бәйрәмдә бер-береңә (друг другу) матур сүзләр әйтәләр. Бу комплиментларның сиңа кайсы (который) ошый?

— Костюм сиңа килешә (подходит)!
— Сиңа бу костюм бик килешә!
— Синең костюмың матур, яңа!
— Син бүген бик матур!
— Синең көлмәгең матур!
— Синең сумкаң нинди зур, яңа!

**6.** Укытучыларны Белем көне белән котларга өйрән.




**7.** Прочитай, выбери понравившийся диалог. Разыграйте его с соседом по парте.

а) — Исәнме, Радик!
— Сәлам! Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы. Бүген бәйрәм, мин бик шат.
— Мин дә бик шат. Сине бәйрәм белән котлыйм!
— Мин дә сине котлыйм!

ә) — Сәлам, Аня.
— Сәлам, Юля. Син бүген бик матур!
— Әйе, бүген 1 нче сентябрь, бүген бәйрәм.

— Мин сине бәйрәм белән котлыйм!
— Мин дә сине котлыйм!

**8.** Дополни диалог. Поговори с соседом по парте.

а) — Коля, син ничәнче сменада укыйсың?
— ... .
— Мин дә икенче сменада укыйм.

ә) — Саша, син ничәнче сыйныфта укыйсың?
— ... .
— Артур, ә син ничәнче сыйныфта укыйсың?
— Мин дә ... сыйныфта укыйм.

б) — Настя, син кем белән утырасың?
— Мин Алия белән утырам. Ә син?
— Мин ... белән утырам.

**9.** Как скажешь о том, что:

— ты учишься в 3-м классе;
— ты учишься во вторую смену;
— тебе 9 лет;
— ты живёшь в городе Казани?

**10.** Как спросишь у друга:
— в какой школе он учится;
— в какую смену он учится;
— какой праздник был в школе;
— кого он поздравил;
— кому он подарил цветы?

## 4–5 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| **Кая?** — Куда? | **Кайда?** — Где? | **Кайдан?** — Откуда? |
|---|---|---|
| **-га/-гә**<br>**-ка/-кә** | **-да/-дә**<br>**-та/-тә** | **-дан/-дән**<br>**-тан/-тән**<br>**-нан/-нән** |

2. Сорауларга җавап бир.

**Син кайда яшисең?**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | Казан... | ? | -та | яшим. |
| | Зәй... | | -тә | |
| | Мамадыш... | | -да | |
| | Әлмәт... | | -дә | |

**Син кайда уйныйсың?**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | мәктәп... | ? | -да | уйныйм. |
| | парк... | | -тә | |
| | урам... | | -дә | |
| | бәйрәм... | | -та | |

**Син кайдан кайтасың?**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | Казан... | ? | -нән | кайтам. |
| | Чирмешән... | | -нан | |
| | Балтач... | | -дән | |
| | Әлмәт... | | -тән | |
| | Чаллы... | | -дан | |
| | Минзәлә... | | -тан | |

**3.** Марат нишли?




**4.** Используя рисунки упражнения 3, составь три диалога. Поговори с соседом по парте.

**5.** Как скажешь о том, что ты:

— идёшь на стадион;
— играешь на стадионе;
— возвращаешься со стадиона?

**6.** Дополни диалог. Поговори с соседом по парте.

— ... ?
— Әйе, мин мәктәпкә барам.
— Син мәктәпкә кем белән барасың?
— ... .

**7.** Позови друга:

— пойти на стадион, в школу, в парк;
— поиграть на улице, на стадионе, в парке.

**8.** Сообщи о том, что ты возвращаешься:

— из школы, из парка, со стадиона;
— из города, из района, из деревни.

## 6–7 нче дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

**слово + -мы/-ме = ?**
**Бу кита́пмы?** — Это книга?

**2.** Шурале забыл названия учебных принадлежностей. Помоги ему вспомнить.



**3.** Шурале хочет уточнить названия учебных принадлежностей. Какие вопросы он задаст? Ответь ему, используя слова **әйе, юк.**

**4. Исеңә төшер!**

**миңа́** — мне  **кирәк** — надо
**сиңа́** — тебе  **кирәк түгел** — не надо
**аңа́** — ему (ей) **кирә́кми** — не надо

5. Используя названия учебных принадлежностей, составь диалог. Поговори с соседом по парте.

6. К каким рисункам подходят эти предложения?

1) Сиңа китап кирәкме?
2) Миңа китап кирәк.
3) Бу — минем китабым.






7. Продолжи по образцу.

Образец: Бу дәфтәр кемгә? — Бу дәфтәр Аняга. — Бу дәфтәр аңа.

1) Бу китап Петяга. 2) Бу пенал Сашага. 3) Бу линейка Ләйсәнгә. 4) Бу сумка Алсуга.

8. Используя рисунки упражнения 2:

— попроси дать тебе учебные принадлежности;
— спроси у друга, нужна ли ему тетрадь (книга, ...);
— предложи другу эти учебные принадлежности.

9. **Исеңә төшер!**

**ни́чә?** — сколько?

| | |
|---|---|
| **1 — бер** | **6 — алты́** |
| **2 — ике́** | **7 — җиде́** |
| **3 — өч** | **8 — сигез́** |
| **4 — дүрт** | **9 — тугы́з** |
| **5 — биш** | **10 — ун** |

**10.** Продолжи диалог. Поговори с соседом по парте.



— Сәлам, Саша!
— Сәлам, Булат!
— Сиңа дәфтәр кирәкме?
— Әйе, кирәк.
— Ничә дәфтәр кирәк?
— … .
— Ә китап кирәкме?
— … .
— Ничә китап кирәк?
— … .



## 8–9 нчы дәресләр

**1.** Рәсемгә кара һәм әйт: нинди карандашлар бар? Алар ничә?

**2.** **Исеңдә калдыр!**





**озы́н** — длинный
**кыска́** — короткий

**3.** 2 нче күнегүдәге рәсемгә кара һәм әйт: нинди карандашлар озын, нинди карандашлар кыска?

**4.** Спроси у друга, нужны ли ему карандаши; узнай, какие карандаши ему нужны; предложи ему эти карандаши.

**5. Исеңдә калдыр!**





**шакмаклы́ дәфтә́р**



**сызыклы́ дәфтә́р**

**6.** Как скажешь о том, что:

— у тебя есть тетрадь в линейку;
— у тебя нет тетради в клетку;
— тебе не нужна тетрадь в линейку, а нужна тетрадь в клетку?

**7. Исеңә төшер!**

**-лар/-ләр, -нар/-нәр** —
аффиксы множественного числа:

китáп — китап**лáр**
дәфтә́р — дәфтәр**лә́р**
урмáн — урман**нáр**
көн — көн**нә́р**

В татарском языке имя существительное при числительных употребляется в единственном числе: **өч алмá, биш дәфтә́р, дүрт карандáш.**

8. Саннар нинди төстә?




9. Дополни диалог. Поговори с соседом по парте.

— Сиңа кызыл карандаш кирәкме?
— … .
— Сиңа нинди карандаш кирәк?
— … .
— Сиңа ничә дәфтәр кирәк?
— … .

10. **Исеңдә калдыр!**

**ала́м** — беру **сала́м** — кладу

11. Рәсемнәргә кара, җөмләләр төзе.



12. Используя рисунки упражнения 11, составь диалог. Поговори с соседом по парте.

## 10–11 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**Исе́м** — имя существительное

Имена существительные обозначают предметы и отвечают на вопросы **кем?** (кто?) и **нә́рсә?** (что?).

В татарском языке, в отличие от русского языка, на вопрос **кем?** отвечают только имена существительные, обозначающие людей. Н а п р и м е р: **эни́, эти́, кыз, мала́й, укучы́.**

Все остальные существительные отвечают на вопрос **нә́рсә?**

**2.** Назови изображённые на рисунках предметы. Слова, отвечающие на вопрос **кем?,** напиши в первый столбик, на вопрос **нәрсә?** — во второй.



| Кем? | Нә́рсә? |
|---|---|
| … | … |

**3.** Прочитай диалог. Разыграйте его с соседом по парте.

а) — Исәнме, Радик!
— Исәнме, Артур!
— Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы. Син кая барасың?
— Мин өйгә кайтам. Ә син кая барасың?
— Башта (вначале) өйгә кайтам, ә аннан соң (потом) стадионга барам. Син киләсеңме?
— Әйе.

ә) — Олег, син ничәнче сменада укыйсың?
— Беренче сменада.
— Әйдә стадионга барабыз.
— Кемнәр бара?
— Дамир, Петя, Әмир, Булат.
— Ярый, мин дә барам.

**4. Исеңдә калдыр!**

мой (моя) — **мине́м** китаб**ы́м**, көндәлег**е́м**
твой (твоя) — **сине́ң** китаб**ы́ң**, көндәлег**е́ң**
его (её) — **аны́ң** китаб**ы́**, көндәлег**е́**

Согласные звуки **[к], [қ], [п]** в конце слов при добавлении аффиксов **-ым/-ем, -ың/-ең, -ы/-е** чередуются со своими звонкими парами **[г], [ғ]** и **[б]**:

көндәле́**к** — көндәле**г**е́м   күлмә́**к** — күлмә**г**е́м
урынды́**к** — урынды**г**ы́м   ту**п** — ту**б**ы́м

**5.** Синең нинди уку-язу әсбапларың (учебные принадлежности) бар? Аларны дәфтәреңә яз.

6. Спроси у соседа по парте:

а) есть ли у него тетрадь в клетку (в линейку), цветные карандаши;

б) где находится его сумка.

7. Спиши, вставляя вместо рисунков нужные слова.

1) Минем яңа  бар. 2) Мин сумкага  салам. 3) Ира миңа  бирә.

8. Составь диалог по содержанию упражнения 7.

9. Перескажи содержание упражнения 7 соседу по парте.

10. Бәйрәмдә кешеләр бер-берсенә (друг другу) комплиментлар әйтәләр. Бу комплиментларның сиңа кайсы (который из них) ошый?



— Син бүген бик матур!

— Синең көлмәгең матур!

— Синең сумкаң яңа!

— Костюмың сиңа килешә (подходит)!

— Сиңа бу костюм бик килешә!

11. Укытучыгызга, бер-берегезгә (друг другу) комплиментлар әйтегез.

## 12–13 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**Фигыль** — глагол

Глаголы обозначают действие предметов и отвечают на вопросы **ни́шли?** (что делает?), **ни́шләде?** (что сделал?), **ни́шләячәк?** (что сделает?).

**Хәзерге заман хикәя фигыль** — настоящее время глагола

**ни́шли?** — что делает?

Говорить о действиях, которые происходят сейчас, помогают аффиксы **-а/-ә; -ый/-и**, которые присоединяются к начальной форме глагола:

бар+**а́** — бара́ (идёт)
кил+**ә́** — килә́ (приходит)
аш(а)+**ы́й** — ашы́й (ест)
сөйл(ә)+**и́** — сөйли́ (говорит)

**2.** Сүзләрне дөрес укы. Тәрҗемә ит.

Ач [а°ч], тор [тŏр], куй [куй], ят [йа°т], йөгер [йө́гөр], укы [у́кы], җырла [җы́рла], тыңла [ты́ңла].

**3.** Представь, что ты тренер. Скомандуй: «беги!», «сядь!», «ложись!», «встань!», «прыгай!», «выходи!».

**4.** Спиши слова, выдели аффиксы настоящего времени глагола.

Чыга, керә, әйтә, сөйли, яза, тыңлый, укый, бара, саный, җырлый.

**5.** С данными глаголами составь 5 предложений.

Укый, яза, килә, эшли, сөйли, бирә, ала, сала, килә, китә.

**6.** Дополни диалог. Разыграйте его с соседом по парте.

— ... ?
— Мин стадионга барам.
— Стадионда нишлисең?
— ... .

**7.** Составь диалоги по образцу упражнения 6 со словами **мәктәп, цирк.** Поговорите друг с другом.

**8. Исеңдә калдыр!**

**бүге́н** — сегодня
**иртәгә́** — завтра
**кичә́** — вчера

**9.** Как надо спросить, чтобы получить такие ответы? Поговорите с соседом по парте.

— ... ?
— Бүген 5 нче сентябрь. Сишәмбе.
— ... ?
— Бүген Наилә дежур.
— ... ?
— Кичә Ира дежур иде.
— ... ?
— Иртәгә Коля дежур.

## 14–16 нчы дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**Үткә́н зама́н хикәя́ фигы́ль** —
прошедшее время глагола

**ни́шләде?** — что сделал?

Говорить о действиях, которые уже произошли, помогают аффиксы **-ды/-де, -ты/-те**, которые присоединяются к начальной форме глагола:

Мин бар+**ды́**+м, кил+**де́**+м.
Син бар+**ды́**+ң, кил+**де́**+ң.
Ул бар+**ды́**, кил+**де́**.

**2.** Найди предложения, соответствующие рисункам.







Предложения: Рәсим язды. Ренат укыды. Алсу сикерде.

**3.** Прочитай слова. Выдели глаголы прошедшего времени. Составь предложения с данными словами.

Бара, язды, барды, яза, укый, укыды, сикерә, ала, бирә, бирде, алды, сикерде.

**4. Исеңдә калдыр!**



**билгé** — отметка
**нúнди?** — какой? какая? какие?
**нúчәле? нúнди билгé?** — сколько? какую отметку?

**«5» — бишлé** **«3» — өчлé**
**«4» — дүртлé** **«2» — икелé**

**. — ноктá** **, — өтéр** **? — сорáу**

5. Разыграйте диалоги.

1) — Без бүген диктант яздык.
— Нинди билге алдың?
— Дүртле.

2) — Син бүген билге алдыңмы?
— Әйе. Математикадан (по математике).
— Ничәле?
— Дүртле.

3) — Бүген расписаниедә нинди дәресләр булды (были)?
— Математика, татар теле, рус теле, физкультура.
— Бүген 4 дәрес булдымы?
— Әйе, бүген 4 дәрес булды.

## 17–19 нчы дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укы.

Кечкенә [кә̆чкә̆нә́], укучы [уқучы́], хата [хаᵒта́], хатасыз [хаᵒтасы́зᶜ], тикшердек [тикшә̆рдә̆́к].

**2.** Тәрҗемә ит. Җөмләләр уйла.

хата — ...
хатасы бар — ...
хата белән — ...
хатасыз — ...
хатасы юк — ...

**3.** Сүзләрнең антонимнарын тап.

кечкенә — ...
җиңел — ...
чиста — ...
матур — ...

**4.** **Исеңдә калдыр!**



Без бар+**ды́**+к.
Сез бар+**ды́**+гыз.
Ала́р бар+**ды**+ла́р.

Без кил+**де́**+к.
Сез кил+**де**+ге́з.
Ала́р кил+**де**+ләр.

**5.** Текстны укы, исем бир.



Без бүген дәрестә кечкенә диктант яздык. Диктант җиңел булды. Без диктантны дәрестә тикшердек. 4 укучы — бишле, 6 укучы — дүртле, 3 укучы өчле алды. Минем дустым Олег чиста, хатасыз язды. Ул бишле алды. Ә минем 2 хатам бар иде. Мин дүртле алдым.

**6.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Диктант җиңел иде. 2) Минем дустым Олег чиста, хатасыз язды. 3) Без бүген дәрестә кечкенә диктант яздык. 4) Мин дүртле алдым.

**7. Исеңдә калдыр!**

**чө́нки** — потому что
**лə́кин** — но
**бá́р иде** — было

Олег бишле алды, **чөнки** хатасыз язды. — Олег получил пятёрку, **потому что** написал без ошибок.

Оля чиста язды, **лəкин** бер хатасы бар иде. — Оля написала чисто, **но** была одна ошибка.

**8.** Вставь пропущенные реплики в диалог. Поговори с соседом по парте.

— Син диктанттан (по диктанту) ничәле алдың?
— ... .
— Ничә хатаң бар иде?
— ... . Ә син нинди билге алдың?
— ... , чөнки хатам бар иде.
— Ничә хатаң бар иде?
— ... .




**9.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Саша «4»ле алды, чөнки ... .
2) Маша «5»ле алды, лəкин ... .

## 20–21 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**сорау бирә** [сŏра́°w бирә́] — задаёт вопрос
**җавап бирә** [җа°wа́п бирә́] — отвечает
**хата төзәтә** [ха°та́ төзәтә́] — исправляет ошибку
**мәсьәлә чишә** [мәсәлә́ чишә́] — решает задачу
**мисал эшли, чишә** [миса́л эшли́, чишә́] – решает пример

**2.** Бу эшләрне кем эшли? Үрнәк буенча әйт.

Күнегү эшли, сорау бирә, җавап бирә, күрсәтә, укый, сөйли, тыңлый, хата төзәтә, рәсем ясый, аңлата.

Үрнәк:
Укытучы сорау бирә. Укучы күнегү эшли.

**3. Исеңә төшер!**

В татарских словах гласные бывают или только мягкие, или только твёрдые. Например: **киләләр, китәләр, баралар, кайталар.**

Исключение составляют заимствованные слова. Например: **китап, пенал, кепка.**

**4. Исеңдә калдыр!**

**үзе́м** — сам(а)
Мин **үзе́м** эшлим. — Я сам(а) делаю.
Син **үзе́ң** эшлисең. — Ты сам(а) делаешь.
Ул **үзе́** эшли. — Он (она) сам(а) делает.

**5.** Сравни данные парами слова и словосочетания. Чем они отличаются друг от друга?

| | |
|---|---|
| хикәя укый<br>хикәя укыйлар | җавап бирә<br>җавап бирәләр |
| сорау бирә<br>сорау бирәләр | аңлата<br>аңлаталар |
| мисал эшли<br>мисал эшлиләр | белге ала<br>белге алалар |

**6.** Как скажешь, если действия упражнения 5 выполнил ты?

**7.** Спроси у друга, сам ли он:

— задал вопрос;
— ответил;
— решил пример;
— сделал упражнение.




**8.** Сүзләрне дөрес укы.

Иптәше [иптәшә̆́], өченче [өчөнчө́], укыды [уқы̆ды̆́], чиште [чиштә̆́], хикәя [хикәйә́], Равил [раᵒwи́л], аңлады [аᵒнҗлады̆́], аңлата [аᵒңлата́], күчерә [күчә̆рә́], ярдәм [йәрдә́м], дөрес [дөрө́с].

**9.** Хикәяне укы. Зөфәр нинди хата ясады?

## Чын иптәш

Закирның ике иптәше бар: Равил һәм Зөфәр. Алар өченче сыйныфта укыйлар.

Балалар өйдә хикәя укыдылар һәм мисаллар чиштеләр.

Закир хикәяне укыды, ләкин мисалларны чишмәде. Ул икенче көнне мәктәпкә килде һәм иптәшләреннән ярдәм сорады. Зөфәр үз дәфтәрен аңа бирде дә:



— Мә, күчер, мин мисалны дөрес эшләдем, — диде.

Ә Равил:

— Юк, Закир, күчермә. Мин сиңа хәзер үзем аңлатам, син үзең эшлә, — диде.

Мәрьям Галләмова

**иптәш** (дус) — друг
**ярдәм сорады** — попросил помощи
**аңлатам** — объясню
**чиште** — решил

**10.** Хикәяне сәнгатьле (выразительно) укырга өйрән.

## 22–24 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**ни́шләмәде?** — что не сделал?
Если действия не происходили, то говорят так:
я́з +**ма**+ды — **не** писал
чи́ш+**мә**+де — **не** решал
Мин я́з+**ма**+ды+м, чи́ш+**мә**+де+м.
Син я́з+**ма**+ды+ң, чи́ш+**мә**+де+ң.
Ул я́з+**ма**+ды, чи́ш+**мә**+де.

**2.** Төшеп калган репликаларны өстәп, диалогны укы, партадашың белән сөйләш.

— Син мисалны үзең чиштеңме?
— … .
— … ?
— Юк, мәсьәләне үзем чишмәдем.

**3.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Равил, Зөфәр, Закир өченче сыйныфта укыйлар. 2) Балалар өйдә хикәя укыдылар һәм мисал чиштеләр. 3) Закирның ике иптәше бар. 4) Закир икенче көнне мәктәпкә килде һәм иптәшләреннән ярдәм сорады.

**4.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

1) Балалар чиштеләр. 2) Мин аңлатам. 3) Закир чишмәде.

**5.** Ике раслауның кайсы (который) дөрес? Дөрес раслауны дәфтәргә яз.

1) Укучылар өйдә мәсьәлә чиштеләр.
   Укучылар өйдә мисал эшләделәр.
2) Закир хикәяне укыды, мисалны эшләде.
   Закир хикәяне укыды, мисалны эшләмәде.
3) Зөфәр Закирга дәфтәрен бирде.
   Зөфәр Закирга мисалны аңлатты.

**6.** Скажи, что:

— ты прочитал рассказ, но не решил задачу;
— ты решил задачу и сделал упражнения.

**7.** Спроси у друга:

— сколько примеров он сегодня решил;
— сам ли он решил задачу.

**8.** Диалогларны дустың белән сөйләш.

1) — Олег, син мисалны эшләдеңме?
— Әйе. Ә син?
— Юк, мин эшләмәдем. Миңа ярдәм ит әле.
— Ярый, хәзер аңлатам.

2) — Булат, син мәсьәләне чиштеңме?
— Әйе, үзем чиштем. Ә син?
— Юк, мин чишмәдем. Миңа ярдәм ит әле.
— Әйдә аңлатам.
— Рәхмәт.

3) — Айнур, мин мәсьәләне чишмәдем. Дәфтәреңне бир әле, күчерәм.
— Юк, Костя, мин сиңа аңлатам. Син үзең чиш.
— Рәхмәт.

**9.** Как попросишь помочь тебе? **Запомни!**



| | |
|---|---|
| **Миңá ярдә́м и́т әле**<br>**Миңá бу́лыш әле** | Помоги мне, пожалуйста. |

**10.** Допустим, что ты:

— не решил задачу;
— не решил пример;
— не сделал упражнение.

Скажи об этом. Попроси друга помочь тебе.

**11.** Как ты понимаешь выражения **чын ярдәм** и **ялган ярдәм**? Напиши небольшое сочинение.

1) Закирга кайсы дусты чын ярдәм күрсәтә?
2) Син дустыңа ничек булышасың?

## 25–27 нче дәресләр

**1.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй.

| | |
|---|---|
| Мин саный... . | Без саный... . |
| Син саный... . | Сез саный... . |
| Ул саный. | Алар саный... . |

**2.** **Исеңдә калдыр!**



| | |
|---|---|
| 10 — ун | 60 — алтмы́ш |
| 20 — егерме́ | 70 — җитме́ш |
| 30 — утьі́з | 80 — сиксә́н |
| 40 — кырьі́к | 90 — туксә́н |
| 50 — илле́ | 100 — йөз |
| 1000 — мең | |

**3.** Саннарны дөрес әйтергә өйрән.

| | | |
|---|---|---|
| 1 — бер | 2 — ... | 9 — ... |
| 11 — ... | 22 — ... | 99 — ... |
| 111 — ... | 222 — ... | 999 — ... |
| 1111 — ... | 2222 — ... | 9999 — ... |

**4.** Дәвам ит.

| | | |
|---|---|---|
| 31 — утыз бер | 32 — ... | 33 — ... |
| 131 — ... | 132 — ... | 133 — ... |
| 1331 — ... | 1332 — ... | 1333 — ... |

**5.** Мисалларны чиш:

100+200=? 121+221=?

1000+2000=? 1121+2221=?

**! 6.** **Исеңә төшер!**



**пять тетрадей** — биш дәфтә́р
**три девочки** — өч кыз

**ни́чә?** — сколько? **ни́чәнче?** — который?

**7.** Саннарны үрнәк буенча дәвам ит.

12, 13, 14, 15

Үрнәк:

11 — унберенче
111 — йөз унберенче
1111 — бер мең бер йөз унберенче

**8.** Спроси у друга:

— в каком году он родился;
— в каком году начал учиться.

**9.** Шигырьне укы.

**Бер атнада ничә көн?**

Бер атнада ничә көн?
Бер атнада җиде көн.
Җиде төрле исеме –
Җидесен дә яттан бел:
Дүшәмбе, сишәмбе,
Чәршәмбе,
Пәнҗешәмбе, җомга,
Шимбә, якшәмбе.

Гөлшат Зәйнашева

**җидесен дә** — все семь
**яттан бел** — знай наизусть



## 28 нче дәрес

### Проверь себя!

**1.** Назови дни недели в правильной последовательности.




**2.** Атнаның җиде көнен әйт. Дүшәмбегә, сишәмбегә дәресләр расписаниесен яз.

**3.** К тебе приехал друг. Ты знакомишь его со школой. Как скажешь, что:

— это ваша школа;
— ты учишься в третьем классе;
— ты учишься хорошо?

**4.** Перед новым учебным годом ты пересмотрел свои учебные принадлежности. Оказывается, у тебя нет ручки (тетради, карандаша). Как скажешь об этом маме?

**5.** Вспомни числа.

| | | |
|---|---|---|
| 10 — … | 60 — … | 1000 — … |
| 20 — … | 70 — … | 2000 — … |
| 30 — … | 80 — … | 3000 — … |
| 40 — … | 90 — … | 4000 — … |
| 50 — … | 100 — … | 5000 — … |

**6.** Скажи, что ты:

не слушаешь, не любишь, не идёшь, не говоришь, не поздравляешь, не читаешь, не работаешь.

**7.** Помоги окончаниям найти своё место.

ул

бара — бар...
килә — кил...
китә — кит...
ала — ал...
эчә — эч...
укый — укы...

? **-мый**
**-ми**

**8.** Сообщи другу о том, что:

— сегодня у вас пять уроков;
— сегодня была контрольная работа;
— вы писали диктант;
— ты написал без ошибок;
— Коля написал без ошибок;
— ты получил(а) четвёрку, потому что была одна ошибка;
— ты не получил тройку;
— ты не писал диктант;
— ты не решил задачу.

**9.** Спроси у друга:

— писали ли они сегодня диктант;
— какую оценку он получил за диктант;
— кто писал чисто и без ошибок;
— есть ли у него ошибки.

# КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ

## 29–31 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**Ка́йчан?** — Когда?
**Сәга́ть ни́чә?** — Который час?
**Сәга́ть ике́.** — Два часа.
**Сәга́ть ни́чәдә?** — Во сколько часов?
**Сәга́ть өчтә́.** — В три часа.

**2.** Сәгать ничә?





**3.** Найди в предложениях слова, отвечающие на вопрос **ни́шли?**.

1) Гали йокыдан тора, зарядка ясый, иртәнге ашны ашый. 2) Гали мәктәпкә китә. 3) Гали мәктәптән кайта. 4) Гали дәрес әзерли. 5) Гали ял итә. 6) Гали йоклый.

**4.** Как ты думаешь, во сколько часов Гали совершает действия, указанные в упражнении 3? Сравни со своим режимом дня.

**5.** Измени по образцу глаголы из упражнения 3 и запиши их.

Үрнәк: **Нишли?** тора́ — **Нишләде?** торды́

**6.** Дәвам ит.





1) Мин йокыдан торам.
   Син йокыдан торасың.
   Ул йокыдан тора.
2) Мин зарядка ясыйм.
   Син ... .
   Ул ... .
3) Мин мәктәпкә барам.
   Син ... .
   Ул ... .

**7.** Рәсемгә кара. Гали турында сөйлә.



**8.** Рассмотри рисунки упражнения 6 и спроси у Гали, когда он выполняет эти действия.

Үрнәк: Гали, син кайчан йокыдан торасың?

## 32–33 нче дәресләр

**1.** Измени глаголы по образцу и запиши их.

О б р а з е ц: тора — торды
Г л а г о л ы: зарядка ясый, урын җыя, ашый.

**2.** Слова и словосочетания заблудились. Помоги им найти свои домики.

Йокыдан тордым, сикердем, дәрес әзерләдең, ашадым, йокыдан тордың, чәй эчтем, өйгә кайттың, кино карадым.







**3.** Измени слова по образцу.

О б р а з е ц: Мин сикердем, җырладым.
Син сикердең, җырладың.
Мин сикермәдем, җырламадым.
Син сикермәдең, җырламадың.

С л о в а: торды, эчте, ясады, әзерләде.

**4.** Дополни диалог. Поговори с соседом по парте.

— Син сәгать ничәдә йокыдан тордың?
— ... .
— Син сәгать ничәдә ашадың?
— ... .
— Син сәгать ничәдә мәктәпкә киттең?
— ... .

— Сәгать ничәдә мәктәптән кайттың?
— ... .

**5.** Продолжи по образцу.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 — бер | 2 — ... | 3 — ... | 4 — ... |
| 11 — унбер | 22 — ... | 33 — .... | 44 — ... |
| 111 — ... | 222 — ... | 333 — .... | 444 — ... |
| 1111 — ... | 2222 — ... | 3333 — .... | 4444 — ... |

**6.** Как ответит Марат на вопросы?

— Марат, син бүген сәгать ничәдә йокыдан тордың?
— ... .
— Марат, син бүген сәгать ничәдә футбол уйнадың?
— ... .
— Марат, син бүген сәгать ничәдә кибеткә бардың?
— ... .

**7. Исеңдә калдыр!**



**иртән** — утром
**иртәнге аш** [иртәңгә́ аᵒш] — завтрак
**көндез** — днём
**көндезге аш** [көндөзгә́ аᵒш] — обед
**кич** — вечером
**кичке аш** [кичкә́ аᵒш] — ужин

**8.** Составь свой режим дня и расскажи другу.

1) Сәгать ... йокыдан торам, иртәнге аш ашыйм.
2) Сәгать ... мәктәптә укыйм.
3) Сәгать ... көндезге аш ашыйм.
4) Сәгать ... ял итәм.
5) Сәгать ... дәрес әзерлим.

6) Сәгать ... кичке аш ашыйм.
7) Сәгать ... йоклыйм.

## 34 нче дәрес

**Проверь себя!**

1. Назови числа по порядку.




2. Спиши, вставляя пропущенные окончания.

1) Мин сәгать сигездә мәктәп... барды... . 2) Азат мәктәп... өйгә сәгать бердә кайтты. 3) Наилә бәйрәм... кич кайтты. 4) Син урам... чыктың...?

3. Как изменятся выделенные слова, если действия уже произошли?

Айдар иртән **тора**, зарядка **ясый**, салкын су белән **юына**. Аннан соң чәй **эчә** һәм мәктәпкә **китә**.

4. Расскажи о своём режиме дня.

5. Спроси у друга, во сколько часов он встал, пришёл в школу, вернулся из школы домой, готовил уроки.

# АШХАНӘДӘ



## 35–37 нче дәресләр

1. **Исеңдә калдыр!**



**ашханә́** — столовая
**кәбестә́ ашы́** — щи
**ботка́** — каша
**пешекче́** — повар
**кесә́л** — кисель
**пешерә́** — варит
**токмачлы́ аш** — суп с лапшой

2. Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Ашханә [а°шхәнә́], пешекче [пә̆шә̆кчә̆́], токмачлы [тоқмачлы́], пешер [пә̆́шә̆р], төрле [төрлө́], ботка [бо̆тқа́], кәбестә [кәбә̆стә́].

3. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй.

1) Мин (кая?) ашханә... барам. 2) Мин (кайда?) ашханә... ашыйм. 3) Мин (кайдан?) ашханә... чыгам.

**4. Исеңә төшер!**

**иртәнгé аш** — завтрак
**көндезгé аш** — обед
**кичкé аш** — ужин

Ботка кайчан тәмләнгән?

5. Укы.

### Ашханәдә

Безнең мәктәптә ашханә бар. Пешекче апалар тәмле ашлар пешерәләр. Без көндезге ашны ашханәдә ашыйбыз. Безгә ашханә ошый.

Меню төрле-төрле була. Безгә кәбестә ашы да, токмачлы аш та, ботка да пешерәләр.

Аннан соң без чәй, компот, кесәл эчәбез. Без пешекче апаларга рәхмәт әйтәбез.

6. Җөмләләрне «Ашханәдә» тексты тәртибендә (по содержанию текста) урнаштыр.

1) Безгә кәбестә ашы да, токмачлы аш та, ботка да пешерәләр. 2) Без көндезге ашны ашханәдә ашыйбыз. 3) Безнең мәктәптә ашханә бар. 4) Без пешекче апаларга рәхмәт әйтәбез.

7. Объявляется конкурс на лучшего чтеца текста «Ашханәдә». Не забудь оценить чтение товарища:

дөрес укый — дөрес укымый
яхшы укый — яхшы укымый

**8.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

Үрнәк: Ашханәдә ашыйм.
Мин ашханәдә ашыйм.
Мин бүген ашханәдә ашыйм.
Мин бүген ашханәдә ботка ашыйм.

Җөмләләр: Пешекче пешерә. Без рәхмәт әйтәбез.

**9.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) — Сезнең мәктәптә ашханә бармы?
— … .
— Син нәрсә яратасың?
— … .
— Мин дә ботка яратам.





ә) — Әйдә ашханәгә барабыз.
— … .
— Нигә бармыйсың?
— Мин ашадым инде.

б) — Миңа аш бирегез әле.
— Нинди аш?
— … .

Табын янында әдәпле бул!

**10.** Спроси у друга:

— любит ли он каши;
— вкусно ли варят в столовой суп;
— нравится ли ему в столовой;
— пьёт ли он утром чай;
— ест ли он днём суп.

**11.** Бу ашамлыкларны пешекчеләрдән сора.




**12.** «Ашханәдә» текстын сөйләргә өйрән.

## 38–39 нчы дәресләр

**1.** Ә син бу ризык исемнәрен беләсеңме?



**2.** Рассмотри рисунки упражнения 1:



а) узнай у друга:
— любит ли он эти блюда;
— предложи ему эти блюда;
— нужны ли ему эти блюда;

б) спроси у повара:
— есть ли эти блюда;
— горячие ли они;
— сколько они стоят.

**3. Исеңдә калдыр!**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **бал** | — | мёд | **тәм** | — | вкус |
| **бал+лы́** | — | сладкий | **тәм+ле́** | — | вкусный |
| **бал+сы́з** | — | не сладкий | **тәм+се́з** | — | не вкусный |

**4.** Бу ризыклар нинди? Дәвам ит.

чәкчәк — баллы, суган — … , сок — … , ботка — … , кесәл — … , чөгендер — … , бал — … .

**5.** Кайсы ризык татлы? Кайсы ризык итле? Таблицага яз.

| Баллы ризыклар | Итле ризыклар |
|---|---|
| … | … |

Ризыклар: кош теле, бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, коймак, пилмән, алма пирогы, чәкчәк, токмачлы аш.

**6.** Җөмләләр төзе.

Без — көндез / иртән / кич ? кичке аш / көндезге аш / иртәнге аш — ашыйбыз.

**7.** Вставь в диалог пропущенные реплики. Поговори с соседом по парте.

а) — … ?
— Әйе, мин ботка ашадым.
— … ?

— Дөге боткасы.
— ... ?
— Бик тәмле.

**8.** Предложи другу:

— вместе пообедать;
— пойти вместе в столовую;
— поесть кашу.

**9.** Допустим, к вам пришли гости. Ты их приглашаешь за стол, угощаешь фруктами. Если ты правильно решишь кроссворд, то отгадаешь, кто к вам придёт.



# 40 нчы дәрес

## Проверь себя!

**1.** Татар халык ашлары исемнәрен ата (назови). Син аларның кайсыларын (которые из них) яратасың?

**2.** Как ты скажешь, что:

— завтракаешь дома;
— обедаешь в школе?

**3.** Попроси дать тебе суп с лапшой, рисовую кашу, щи.

**4.** Җөмләләр төзе.

Мин   куям.

**5.** Бу сүзләрне дөрес укы.

Кашык [қа°шы́қ], кул [қул], урын [уры́н], авыз [а°wы́з], урындык [уры̆нды́қ], пычак [пы̆ча́қ].

**6.** Попроси сестрёнку:

— вытереть стол, ложки, нож;
— поставить хлеб на стол;
— раздать ложки, вилки.

# БЕЗ ӘТИ-ӘНИЛӘРГӘ БУЛЫШАБЫЗ

## 41–42 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укы. Гаиләдә ничә кеше?



**Безнең гаилә**

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи — җиденчесе.

Габдулла Тукай

**җидәү** — семеро

**2.** Сорауларга җавап бир.

1) Гаиләдә ничә кеше бар? 2) Алар кемнәр? 3) Песи ничәнче?

**3. Исеңә төшер!**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **миней́м** | абыем́ | апа́м | әнием́ | баба́м |
| **синең́** | абыең́ | апа́ң | әниең́ | баба́ң |
| **аны́ң** | абыйсы́ | апасы́ | әнисе́ | бабасы́ |

**4.** Сезнең гаиләдә кемнәр бар? Сез бергә нишлисез? Үзара сөйләшегез.

**5. Исеңә төшер!**

**-чы/-че** кушымчалары яңа сүзләр ясый:
**бакча+чы́** — садовод
**нефть+че́** — нефтяник
**төзү+че́** — строитель

**6.** Бирелгән сүзләрдән һөнәр (профессия) исемнәре ясa.

Балык, бакча, эш, китапханә, сак.

**7. Исеңдә калдыр!**

Если хочешь сказать о профессии своих родителей, то говори так:
**Минем әтием** — төзүче.
**Минем әнием** — укытучы.
**Минем әнием** — тегүче (швея).

**8.** Рәсемнәргә кара һәм үрнәк буенча әйт: кем нишли?

Үрнәк: Тегүче тегә.



# 43–45 нче дәресләр

**1.** Помоги буквам **ә, е** найти свои места.

Б..зн..ң гаил.. бик зур. Гаил..дә алты к..ш..: ..ти, ..ни, апа, абый, эн..м һ..м мин.

**2.** Переведи по образцу. Составь предложения.

*Образец:* его (её) мама — аның әнисе; әнисе

его (её) папа — ...
его (её) бабушка — ...
его (её) дедушка — аның бабасы; бабасы
его (её) сестра — ...
его (её) брат — ...

**3.** Научись правильно произносить эти слова. Они помогут тебе прочитать рассказ без ошибок.

Үзе [үзә́], тора [тŏра́], урын [уры́н], җыя [җыйа́], ясый [йа°сы́й], файдалы [фа°йдалы́], тәмле [тәмлә́].

**4.** Дөрес тәрҗемәне тап.

| **полезная** | **хвалит** | **одевается** |
|---|---|---|
| 1) пөхтә | 1) шатлана | 1) кия |
| 2) акыллы | 2) юына | 2) кием |
| 3) файдалы | 3) мактый | 3) киенә |

**5.** Текстны укы.

### Акыллы малай

Дима — зур малай. Иртән тора, урын җыя. Зарядка ясый, чөнки зарядка файдалы. Димага

әнисе тәмле чәй бирә. Малай чәй эчә һәм рәхмәт әйтә. Аннан соң киенә, мәктәпкә китә. Ул өйгә көндез кайта һәм өйдә булыша.

**6.** Найди в тексте «Акыллы малай» предложения, соответствующие данным рисункам.



**7.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Димага әнисе тәмле чәй ясый. 2) Дима – зур малай. 3) Дима көндез өйгә кайта. 4) Дима иртән тора, урын җыя.

**8. Исеңә төшер!**

**һәм** — и
**ни́ өчен?** — почему?
**чө́нки** — потому что
**шуңа́ күрә́** — поэтому

1) Мин чәй эчәм һәм мәктәпкә китәм.
2) Минем кулым чиста, **чө́нки** сабын белән юам.
3) Мин кулымны сабын белән юам, **шуңа́ күрә́** ул чиста.

**9.** Җөмләләрне дәвам ит (продолжи).

1) Дима зарядка ясый, чөнки … . 2) Аның кулы чиста, чөнки … . 3) Дима — яхшы малай, чөнки … . 4) Дима китап укый, шуңа күрә … .

**10.** Прочитай диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) — Дима, син иртән сәгать ничәдә торасың?
— Мин сәгать 7 дә торам.
— Зарядка ясыйсыңмы?
— Әйе, зарядка ясыйм.

ә) — Әни, әйдә мин сиңа булышам.
— Ярый. Мин чәй ясыйм, ә син өстәлгә ипи, май куй.

б) — Коля, әйдә бергә өстәл әзерлибез.
— Әйдә. Мин нишлим?
— Син тәлинкәләр, кашыклар куй, ә мин ипи кисәм.

**11.** Найди в тексте «Акыллы малай» действия Димы, за которые его можно похвалить.

**12.** Дима бу эшләрнең кайсын эшләде? Ә син кайсын эшлисең?



## 13. Исеңдә калдыр!

Если хочешь похвалить кого-либо, скажи так:
**Син яхшы́ кыз (мала́й)!**
**Син акыллы́! Син әйбә́т!**

## 14. Дополни диалоги. Разыграйте их с соседом по парте.



а) — … .
— Әйе, мин иртән урын җыям.
— Тагын нишлисең?
— … .
— Син яхшы малай.



ә) — Син әниеңә булышасыңмы?
— … .
— Нәрсә эшлисең?
— … .
— Син яхшы малай.



б) — Петя, син нишлисең?
— … .
— Син яхшы малай. Зарядка бик файдалы (полезна).

## 15. Игра «Похвали меня».

Ход игры: ты говоришь о своём хорошем поступке, а сосед по парте тебя должен похвалить. Потом меняетесь ролями.

## 46–47 нче дәресләр

1. Диалогны укы, иптәшең белән сөйләш.

— Саша, бүген кинога барасыңмы?
— Юк, Дима.
— Ни өчен?
— Мин әнигә булышам. Өйдә эш күп.

2. Как скажешь, что:



— ты помогаешь маме, папе, бабушке, дедушке;
— у тебя много дел, потому что мама на работе;
— у тебя много уроков, но ты помогаешь маме?

3. Разыграйте диалоги. Какой из них тебе больше нравится? Почему так думаешь?

а) — Әбием, әйдә мин сиңа булышам.
— Рәхмәт, улым. Нәрсә эшлисең?
— Савыт-саба юам. Кибеткә барам.
— Ярый, балам.

ә) — Кызым, миңа булыш әле.
— Ярый, әбием. Башта компьютерда уйныйм, аннан соң булышам.

4. Предложи маме отдохнуть. Скажи, что ты сам(а) вымоешь посуду.

5. Похвали своего младшего брата. Скажи, что он уже большой, что он хороший мальчик.

**6.** Шигырьне сәнгатьле укы һәм ятла.



**Дәү әнием**

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул — минем дәү әнием.

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

Әминә Бикчәнтәева

**7.** Похвали сестрёнку за помощь в домашних делах.

## 48 нче дәрес

**Проверь себя!**

**1.** Переведи.

булыша — ...
өстәл әзерли — ...
савыт-саба юа — ...
идән себерә — ...
идән юа — ...
урын җыя — ...
кибеткә бара — ...
ипи алып кайта — ...
эшчән — ...
тырыш — ...
ялкау — ...

2. Расскажи о своей семье.

3. Как скажешь о том, что ты:

— утром делаешь зарядку;
— убираешь постель;
— одеваешься;
— пьёшь чай;
— помогаешь сестрёнке;
— идёшь в школу?

4. Скажи другу, что ты не помыл посуду. Попроси сестру тебе помочь.

5. Расскажи о том, как ты помогаешь в домашних делах.

6. Как скажешь о том, что ты:

— не ходил в магазин;
— не помыл полы;
— не купил молока, хлеба;
— не убирался дома;
— не гладил бельё;
— не включал компьютер;
— не играл на улице?

7. Дополни диалог. Поговори с другом.

— Саша, син әниеңә булышасыңмы?
— Әйе.
— Нишлисең?
— … , … , … .

# ТУГАН КӨН — КҮҢЕЛЛЕ БӘЙРӘМ

## 49–50 нче дәресләр

**1.** Туган көн белән котлауны өйрән!



Настя!
Сине туган көнең белән котлыйм.
Сиңа уңышлар телим.
Дамир

**2.** Скоро встреча с друзьями. Научись вежливо общаться. Выбери реплики, которые говорят:

— при встрече;
— при приглашении к столу;
— при просьбе.

Исәнмесез!

Хәерле көн!

Әйтегез әле.

Сау булыгыз!

Хәерле иртә!

Рәхим итегез!

Зинһар.

Рәхмәт!

Бирегез әле.

Ашыгыз тәмле булсын!

Хәерле кич!

**3.** Текстны укы. Ни өчен текст «Тәмле сүзләр» дип атала?

### Тәмле сүзләр

Безнең телебездә тәмле сүзләр бик күп. Сез аларны беләсез.

Иртән: «Хәерле иртә!» — дип әйтәбез.

Көндез: «Хәерле көн!» — дип әйтәбез.

Кич: «Хәерле кич!» — дибез.

Кич тыныч йокы телибез. «Тыныч йокы, әнием! Тыныч йокы, әтием! Тыныч йокы үземә, тыныч йокы күземә», — дибез.

«Салават күпере» журналыннан

Сүз тәмле буламы?

**4.** К каким рисункам подходят эти диалоги?

1) — Хәерле көн, Булат.
— Хәерле көн, Олег.
— Син кая барасың?
— Стадионга.

2) — Хәерле иртә, Айдар!
— Хәерле иртә, Юля.
— Әйдә мәктәпкә бергә барабыз?
— Әйдә.

3) — Хәерле кич, Камилә!
— Исәнме, Марат.
— Хәлләрең ничек?
— Рәхмәт, яхшы.







**5.** Ты умеешь разговаривать по телефону? Какой из этих диалогов тебе нравится? Какой из них ты считаешь правильным?



1) — Алло!
— Алло!
— Марат өйдәме?
— Ә кем сорый?
— Дима. Миңа Марат кирәк.
— Хәзер чакырам.

2) — Алло, Альбина апа, исәнмесез! Бу мин — Дима. Марат өйдәме?
— Өйдә.
— Чакырыгыз әле.
— Хәзер чакырам.
— Рәхмәт.

3) — Алло, Олег, нигә стадионга килмәдең?
— Авырыйм.
— Кайчан киләсең?
— Белмим.

4) — Сәлам, Олег. Хәлләр ничек?
— Сәлам, Муса!
— Олег, нигә стадионга килмәдең?
— Авырыйм.
— Авырма, без сине көтәбез.
— Рәхмәт.



## 51–54 нче дәресләр

**1.** Туган көнгә ничек чакырасың? Син кайсы чакыруны сайлыйсың?



а) — Алло, хәерле кич!
— Хәерле кич!
— Оля, синме?
— Әйе, мин.
— Оля, якшәмбе көнне минем туган көнем. Вакытың бармы? Мин сине чакырам.



— Сәгать ничәдә?
— Көндез сәгать уникедә.
— Рәхмәт. Мин киләм.

ә) — Алло, Костя, сәлам!
— Сәлам, Наил.
— Костя, якшәмбе көнне туган көнгә кил. Онытма!
— Ярый, Наил, киләм.

**2.** Кроссвордны чиш. Марат туган көнгә нинди чәчәкләр алып килә?









**3.** Рәсемгә кара һәм әйт: туган көнгә кемнәр килде һәм аларга ничә яшь?



Наил



Оля



Руслан



Катя

**4.** Рәсемгә кара һәм әйт: кем нинди бүләк алып килде?









**5.** Расположи диалоги по порядку проведения дня рождения.

1) — Мин кул юам?
— Ярый, менә сөлге.
— Рәхмәт.

2) — Наил, без сине туган көнең белән котлыйбыз! Сиңа бүләк алып килдек.
— Нинди матур бүләкләр, рәхмәт сезгә! Әйдәгез табын янына утырыгыз.

3) — Исәнмесез, мөмкинме?
— Әйдәгез керегез, чишенегез, утырыгыз.
— Рәхмәт.

4) — Нинди матур табын!
— Әйдәгез чәй эчегез! Нәрсә белән эчәсез?
— Лимон белән.
— Менә өчпочмак алыгыз.
— Нинди тәмле өчпочмак!

**6.** Допустим, к тебе на день рождения пришли друзья. Расставь картинки по порядку и составь предложения.



**7.** Составьте сценарий на тему «День рождения» и разыграйте его.

**8.** «Әпипә» такмагын (частушку) өйрән.

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам,
Әпипәнең көйләренә
Биеп калыйм ичмасам.

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам,
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам.

## 55 нче дәрес

**Проверь себя!**

**1.** Син телефоннан сөйләшә беләсеңме? Диалогларны укы, иптәшең белән сөйләш.

1) — Алло, Альбина апа, исәнмесез! Бу мин — Олег. Ә Марат өйдәме?
— Өйдә.
— Маратны чакырыгыз әле.

2) — Алло, Сания апа, исәнмесез! Сезне Лена борчый. Миңа Алсу кирәк иде.
— Алсу өйдә юк әле.
— Ә кайда?
— Тренировкада.
— Ярый, рәхмәт. Сау булыгыз!

**2.** Спроси у друга:

— когда у него день рождения;
— сколько ему лет;
— отмечает ли он день рождения;
— кого он пригласит на день рождения;
— во сколько начинается праздник.

**3.** Пригласи друга сесть за стол и угости его чаем, тортом.



**4.** Ты был в гостях, и тебя угостили вкусными пирогами. Как поблагодаришь хозяев?

# ЯРАТКАН УЕННАРЫМ



## 56–58 нче дәресләр

**1.** Шигырьләрне укы. Ошаса, ятла.

**Салкын, саф һава**

Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява,
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Әминә Бикчәнтәева



**2.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

Кыш [қЫш], салкын [саºлқЫ́н], кыска [қЫсқа́], кар [қаºр], ап-ак [а́ºп̄ақ], йомшак [йŏмша́қ].

**3.** Найди в тексте стихотворения слова, отвечающие на вопрос **ни́нди?**.

**4. Исеңдә калдыр!**

**Сыйфа́т** — имя прилагательное

Имена прилагательные обозначают признаки предметов и отвечают на вопрос **ни́нди?** (какой? какая? какое?)

**салкы́н** кыш (холодная зима), **ак** кар (белый снег), **кыска́** көн (короткий день), **көчле́** җил (сильный ветер).

**5.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.



а) — Бүген көн нинди?
— ... .
— Ничә градус салкын?
— ... .
— Ә җил бармы?
— Әйе, көчле җил исә.



ә) — Бүген көн нинди?
— ... .
— Ә температура нинди?
— ... .

**6.** Диалогны тәрҗемә ит. Дустың белән сөйләш.

— Коля, выходи на улицу.
— Я не выйду.
— Почему?
— Потому что очень холодно, дует сильный ветер.



**7.** Текстны укы.

### Тауда

Вәли һәм Нәсим тау ясадылар. Ә Сәлим урамга чыкмады, өйдә утырды, чөнки ул авырды. Тау биек, зур булды. Вәли чана шуды, Нәсим чаңгы шуды. Малайларга бик күңелле булды.

Икенче көнне Сәлим дә тауга килде.

— Шума, бу синең тавың түгел! — диде Вәли.

— Шу, Сәлим, син дә шу, — диде Нәсим.

«Гөлбакча» китабыннан

**биек** — высокий
**күңелле** — весело
**диде** — сказал
**булды** — было
**чыкмады** — не вышел
**икенче көнне** — на другой день

**8.** Расположи предложения по содержанию текста «Тауда».

1) Тау биек, зур булды. 2) Вәли белән Нәсим тау ясадылар. 3) Сәлим өйдә утырды, чөнки ул авырды. 4) Вәли һәм Нәсим тауда чана, чаңгы шудылар.

**9.** Какие из этих предложений соответствуют содержанию текста «Тауда»?

1) Вәли белән Нәсим Кар бабай ясадылар. 2) Вәли белән Нәсим тау ясадылар. 3) Сәлим урамда уйнады. 4) Сәлим урамда уйнамады. 5) Нәсим һәм Вәли тимераякта шудылар. 6) Вәли чана шуды, Нәсим чаңгы шуды.

**10.** Кто быстрее и лучше читает?

Сәлим чыкмады.
Сәлим урамга чыкмады.
Сәлим урамга чыкмады, өйдә утырды.
Сәлим урамга чыкмады, өйдә утырды, авырды.

**11.** Поставь вопросы к предложениям текста «Тауда».

**12.** Конкурс на лучшего рассказчика текста «Тауда».



| | |
|---|---|
| Сәнгатьле сөйли.<br>Сүзләрне дөрес әйтә.<br>Хата ясамый.<br>Яхшы сөйли. | Сәнгатьле сөйләми.<br>Сүзләрне дөрес әйтми.<br>Хата ясый.<br>Яхшы сөйләми. |

**13.** Напиши, как бы ты продолжил рассказ.

**14.** Расскажите друг другу свои рассказы.

## 59–61 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куй. Текстны сөйләргә өйрән.

Дима, Азат, Әмир — дуслар. Алар һәрвакыт бергә уйныйлар.

Бүген көн җылы, җил юк,  ява. Дима  ала, Азат белән Әмир  алалар. Малайлар бик озак  шуалар. Аннан соң бергә дәрес әзерлиләр.

**2.** Иң яхшы хикәя сөйләүчегә конкурс! Бәя бирергә онытма!

**3.** Выпиши из текста глаголы, поставь их в прошедшем времени. Расскажи содержание текста, используя глаголы прошедшего времени.

**4.** Составь диалог по тексту. Поговори с соседом по парте.

**5.** Предложи другу:

— поиграть вместе на улице;
— покататься вместе на лыжах;
— поиграть в хоккей.

**6.** Рәсемнәр урынына сүзләр куй, диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

а) — Таня, әйдә урамга чыгабыз.

— Әйдә. Ә  барабызмы?

— Әйдә бүген шугалакка барабыз! Синең  бармы?

— Бар. Әнием миңа яңа  бүләк итте.

ә) — Илнур, әйдә тауга барабыз,  шуабыз.

— Минем  юк, Сәлим,  гына бар.

— Ярый, Илнур. Мин чана алам, ә син чаңгы ал. Мин сине тау янында көтәм.

б) — Марат, бүген хоккей уйнарга чык!

— Сәгать ничәдә?

— 


**7.** Спроси у друга:

— какая сегодня погода;
— холодно ли на улице.

8. Составь рассказ, схожий с содержанием текста упражнения 1.

9. Составь диалог по содержанию своего рассказа. Поговори с соседом по парте.

## 62–64 нче дәресләр

1. Текстны укы һәм аңа исем куй.

Айдар, Петя — дуслар. Алар бергә шахмат һәм шашка уйныйлар. Айдар яхшы уйный, чөнки ул шахмат түгәрәгенә йөри. Петя шашка ярата. Ул бик яхшы шашка уйный. Петя 3 нче сыйныфта укый.

**шахмат түгәрәге** — шахматный кружок



2. Сорауларга җавап бир.

1) Малайлар нинди уеннар уйныйлар?

2) Айдар нинди уен ярата? Ул ни өчен яхшы уйный?

3) Петя нинди уен ярата? Ул ничек уйный?

3. Пригласи друга:

— вместе поиграть;
— пойти на стадион;

— поиграть в шахматы (шашки);
— покататься на велосипеде.

**4.** Рәсемнәрне кара. Җәйге уен төрләрен әйт.



**5. Исендә калдыр!**



**су коена́** — купается
**йөзә́** — плавает
**чума́** — ныряет
**кызына́** — загорает
**көймәдә́ йөзә́** — катается на лодке

6. Рәсемнәргә кара һәм әйт: малай нишли?






7. Укы һәм диалогларны иптәшең белән сөйләш.

— Саша, син кая барасың?
— Елгага.
— Ә син йөзә беләсеңме?
— Мин йөзә беләм, бассейнда өйрәндем. Әйдә безнең белән.
— Юк, бармыйм, мин йөзә белмим.

## 65 нче дәрес

### Проверь себя!

1. Позови друга:

— вместе поиграть на улице;
— вместе покататься на лыжах;
— поиграть в хоккей;
— лепить снеговика.



**2.** Җөмләләр төзе.

Мин  уйныйм.

Мин  дә йөзәм.

Мин  да су коенам.

Мин  та йөрим.

**3.** Как скажешь, что Айрат, Петя, Шамиль — друзья и они вместе играют в футбол?

**4.** Спроси у друга:

— играет ли он в теннис (бадминтон);
— с кем он играет в футбол;
— хорошо ли он катается на велосипеде (на лыжах);
— хорошо ли он плавает.

**5.** «Минем яраткан уеннарым» темасына кечкенә хикәя төзе.






# ШӘҺӘРДӘ ҺӘМ АВЫЛДА

## 66–68 нче дәресләр

**1.** Татарстан картасын кара. Татарстанда нинди шәһәрләр бар? Син кайда яшисең?




Татарстан турында мульт-фильм кара!

**2.** Төрләнешне өйрән.

Мин яши**м** (тора**м**).
Син яши**сең** (тора**сың**).
Ул яши (тора).

Без яши**без** (тора**быз**).
Сез яши**сез** (тора**сыз**).
Алар яши**ләр** (тора**лар**).

**3.** Текстны укы. Шәһәрләрне картадан тап.

Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә, Алабуга, Чистай, Нурлат — Татарстанда зур шәһәрләр.

Мәскәү — Россиянең башкаласы, ә Казан — Татарстанның башкаласы.

Әлмәт — нефтьчеләр шәһәре. Яр Чаллы — автомобильчеләр шәһәре. Алабуга — музейлар шәһәре.




**4.** Таблицаны тутыр.

| Татарстан шәһәрләре | Россия шәһәрләре |
| --- | --- |
| ... | ... |

**5.** Диалогны укы. Иптәшең белән сөйләш.

1) — Азат, син кая барасың?
— Казанга.
— Кем белән?
— Әти белән. Ә син кая барасың?
— Мәскәүгә. Без гаилә белән кунакка барабыз.

2) — Петя, әйт әле, Алабуга зур шәһәрме?
— Әйе. Алабуга — матур, зур шәһәр. Анда музейлар күп. Без бөек рәссам И.И. Шишкин музеена бардык.



**6.** Нокталар урынына тиешле кушымчалар куй. Текст эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

Мин Зәй... яши... , ә дустым Коля Әлмәт... яш... . Аның әтисе — нефть... , ә әнисе — сату... . Коля каникулда без... кил... . Мин аны көт... .

**7.** Скажи, что:

— ты живёшь в Казани;
— Казань — большой красивый город;
— ты едешь в Казань на автобусе.

## 69–71 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**шәһә́р** — город **Каза́н шәһәре́** — город Казань
**ура́м** — улица **Ба́уман урамы́** — улица Баумана

**2.** Дәвам ит.

Ү р н ә к: Бу нинди шәһәр? — Бу — Әлмәт шәһәре.

Казан, Чистай, Мәскәү, Яр Чаллы, Алабуга, Самара, Түбән Кама, Санкт-Петербург.

**3. Исеңдә калдыр!**



— Бу ни́нди ура́м?
— Бу — Ба́уман урамы́.
— Син ка́йсы урамда́ яши́сең?
— Мин Ба́уман урамында́ яши́м.

**4.** Үрнәк буенча дәвам ит.

Үрнәк: — Син кайсы урамда яшисең?
— Мин Мәскәү урамында яшим.

Урам исемнәре: Сөембикә, Чулман, Тукай, Тынычлык, Кол Гали, Пушкин.

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй, дәфтәреңә яз, җөмләләргә сораулар яз. Сораулар буенча үзара сөйләшегез.

1) Әлмәт шәһәр... бик матур. 2) Костя нинди шәһәр... яши? 3) Костя Чистай... яши. 4) Алсу, син нинди шәһәр... яши...? 5) Китап кибете Бауман урамы... урнашкан.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нәрсәдә бара?

Азат  ... . Дима  ... . Алсу  ... .

**7.** Нокталар урынына **тора, яши** сүзләрен куеп укы.

Мин барам, ... , ... .
Син барасың, ... , ... .
Ул бара, ... , ... .

Без барабыз, ... , ... .
Сез барасыз, ... , ... .
Алар баралар, ... , ... .

**8.** Нокталар урынына кушымчалар өстә. Дәфтәреңә яз.

Мин / Арча... яшим.
Мин – Арча... килдем.
Мин \ Арча... барам.

Мин / Казанга поезд... барам.
Мин – Арчага машина... барам.
Мин \ Әлмәткә автобус... барам.

# 72–74 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**йорт** — дом
**фати́р** — квартира
**кат** — этаж

2. Кем ничәнче катта яши?



 — Азат  — Дамир  — Маша  — Алсу

 — Катя  — Айгөл  — Олег

3. Помоги Гали перевести вопросы.

**нәрсә?**
**ничә? ничәнче?**
**ничек? нинди?**
**кайсы? кайда?**



**4.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә. Дустың белән сөйләш.

а) — Син кайсы урамда яшисең?
— ... .
— Син ничәнче йортта торасың?
— ... .
— Син ничәнче фатирда торасың?
— ... .

ә) — ... ?
— Мин бишенче мәктәптә укыйм. Ә син?
— ... .

**5.** Сорауларга җавап яз. Сөйләргә өйрән.

1) Син кайсы шәһәрдә яшисең?
2) Син кайсы урамда торасың?
3) Син кайсы йортта, ничәнче катта, ничәнче фатирда торасың?
4) Ничәнче мәктәптә укыйсың?

**6.** Составь диалог по содержанию упражнения 5. Поговорите друг с другом.

**7.** Рәсемнәр урынына сүзләр куеп укы.

1) Мин мәктәпкә  барам, ә әни  бара.

2) Безнең  янында 

бар.

3) Шәһәрдә 

, 

, 

бар.

## 75–77 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**бүлмә́** — комната
**йокы́ бүлмәсé** — спальня
**аш бүлмәсé** — кухня
**куна́к бүлмәсé** — зал

2. Фатирда нинди бүлмәләр бар? Бүлмәдә нәрсәләр бар?







**3.** Текстны укы.

Бу безнең фатир. Анда ике бүлмә бар: кунак бүлмәсе һәм йокы бүлмәсе. Аш бүлмәсендә зур өстәл бар. Без анда ашыйбыз. Безнең кунак бүлмәсе бик зур. Анда диван, телевизор, шкаф бар. Безнең йокы бүлмәсе дә зур. Анда ике зур карават бар. Бер караватта мин йоклыйм, икенче караватта абыем йоклый.

**4.** Бу предметлар кайсы бүлмәдә тора?



**5.** Диалогларны укы. Партадашың белән сөйләшегез.

— Костя, әйдә безгә кунакка барабыз.
— Син кайда яшисең?
— Мин Пушкин урамында яшим.
— Ничәнче йортта яшисең?
— 10 нчы йортта яшим.
— Ничәнче катта яшисең?
— 3 нче катта, 12 нче фатирда яшим.

**6.** Диалогны укы. Партадашың белән сөйләшегез. Үзегезнең фатирыгыз турында сөйлә.

— Әминә, сезнең фатир зурмы?
— Зур түгел.
— Ничә бүлмә бар?
— Ике бүлмә: кунак бүлмәсе һәм йокы бүлмәсе бар.
— Ә аш бүлмәсе зурмы?
— Аш бүлмәсе дә зур, юыну бүлмәсе дә зур.

**7.** Үзегезнең фатирыгыз турында сөйләргә өйрән.

## 78–80 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**һәр** — каждый, **алдында́** — спереди (впереди), **артында́** — сзади (позади), **янында́** — возле (рядом)

**2.** Рәсемгә кара һәм сорауларга җавап бир.

1) Өй алдында нәрсә бар?
2) Өй артында нәрсә бар?
3) Өй янында нәрсә үсә?



**3.** Текстны укы.

### Безнең авыл

Без авылда яшибез. Авылда йортлар бик матур. Һәр йорт янында бакча бар. Анда алмагачлар, чияләр

үсә. Йортлар артында бәрәңге һәм яшелчә бакчасы бар. Анда бәрәңге, кишер, суган, чөгендер үсә.

Авылда яңа мәктәп бар. Мәктәп алдында чәчәкләр күп. Мәктәп артында спорт мәйданы бар. Анда балалар уйныйлар.

**4.** Кайда нәрсә бар? Җөмләләрне дәвам ит.

1) Һәр йорт янында … . 2) Йортлар артында … . 3) Мәктәп алдында … . 4) Мәктәп артында … .

**5.** Ике раслауның кайсысы дөрес? Дөрес раслауны дәфтәреңә яз.

1) Һәр йорт янында бакча бар.
   Һәр йорт янында бакча юк.
2) Бакчада алмагачлар, чияләр үсә.
   Бакчада алмагачлар, чияләр үсми.

**6.** Дополни диалог. Разыграйте его с другом.

— … ?
— Мин каникулда авылга кайтам. … ?
— Мин дә авылга кайтам.
— Авылда кем яши?
— … .

**7.** Используя содержание текста «Безнең авыл», составь диалоги. Поговорите с соседом по парте.

**8.** Диалогны укы. Партадашың белән сөйләшегез.

— Айнур, син кайда яшисең?
— Мин авылда яшим.
— Нинди районда?

— Балтач районында.
— Нинди авылда?
— Карадуган авылында.
— Авылыгыз матурмы?
— Әйе, матур. Авыл янында елга бар. Без анда су керәбез.
— Ә урман бармы?
— Әйе, урман да бар. Без анда җәй көне җиләк, гөмбә җыябыз.

Габдулла Тукай «Туган авыл»

**урман да бар** — и лес есть

**9.** Составь маленький рассказ о деревне.

## 81 нче дәрес

### Проверь себя!

**1.** Ты не забыл татарские названия этих городов? Составь с ними предложения.

Казань, Чистополь, Заинск, Набережные Челны, Елабуга, Нижнекамск, Альметьевск, Бугульма, Мензелинск.

**2.** Таблицаны тутыр.

| Татарча | Русча |
|---|---|
| | |

Шәһәр исемнәре: Казан, Мәскәү, Уфа, Чистай, Саратов, Алабуга, Самара, Зәй, Салават, Түбән Кама, Минзәлә, Бөгелмә, Баулы.

**3.** Спроси у друга:

— в каком городе он живёт;
— на какой улице его дом;
— на каком этаже его квартира;
— на чём он едет в школу;
— есть ли в деревне школа;
— большая ли у них деревня.

**4.** Расскажи о своём городе или о своей деревне.

**5.** Дополни диалоги. Разыграйте их с соседом по парте.

а) — ... ?
— Әйе, безнең шәһәрдә музей бар.
— ... ?
— Шәһәр музее.

ә) — Ләлә, әйдә музейга барабыз.
— Мин риза.
— ... ?
— Сәгать өчтә.

б) — Син кайсы авылда яшисең?
— ... .
— Сезнең авыл зурмы?
— ... .

**6.** Сорауларга җавап бир.

1) Сезнең шәһәрдә нинди транспортлар йөри?
2) Татарстанда нинди шәһәрдә метро бар?
3) Син метрода булдыңмы?

**7.** Расскажи содержание текста «Безнең авыл».

# МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

## 82–83 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**милләт** — национальность
**милли бәйрәм** — национальный праздник
**милли кием** — национальная одежда

**2.** Милләт исемнәрен татарча әйт.

Русские, татары, чуваши, марийцы, мордва, башкиры.

**3.** Рәсемгә кара һәм әйт: балалар нинди киемнәр кигәннәр? Бу киемнәрне нинди милләт кешеләре кия?

Ү р н ә к: Кызыл сарафанны руслар кия.



**4.** Текстны укы. Милли киемнәр турында сөйләргә өйрән.

— Алсу, бу нинди кибет?

— Бу бик матур кибет, Оля. Әйдә керәбез. Мин сиңа матур киемнәр турында сөйлим.

Бу — калфак . Аны татар кызлары кия. Ә бу — түбәтәй . Аны бабайлар да, әтиләр дә, малайлар да кияләр.

Менә читекләр . Читекләрне кызлар, малайлар бәйрәмдә кияләр.

Бу — алъяпкыч . Ул бик матур һәм чәчәкле. Ә бу — камзул . Аны кызлар да, малайлар да, абыйлар да, апалар да кияләр.

**5.** Научись правильно называть национальную одежду татарского народа.

    

**6.** Игра «Түбәтәй».

Түгәрәккә басабыз. Җырлыйбыз:

Түп-түгәрәк түбәтәй,
Түбәтәем укалы,
Чиккән матур түбәтәем
Кемдә икән тукталды?

Җыр җырлаганда, түбәтәй кулдан-кулга күчә. Җыр туктагач, түбәтәй кемдә кала, шуңа җәза бирелә.

**җәза** — здесь: задание

## 84–86 нчы дәресләр



1. Текстны укы. Быел Сабантуй кайчан була?

Сабантуй — Татарстанда иң зур бәйрәм. Сабантуй бик матур урында була. Ул июньдә үтә. Сабантуйга бөтен кеше бәйрәмчә киенә. Бар кеше дә шат. Сабантуйда төрле кызык уеннар була: ат чабышы, чүлмәк вату, баганага менү.

**бәйрәмчә** — по-праздничному
**ат чабышы** — конные скачки
**баганага менү** — лазание на столб
**чүлмәк вату** — разбивание горшка

**2.** Рәсемгә кара һәм әйт: Сабантуйда нинди уеннар була?

**3.** Җөмләләргә төрле вариантларда сораулар куй.

1) Азат белән Руслан көрәшәләр.
2) Нина белән Ира йөгерәләр, ә Алмаз сикерә.
3) Никита чүлмәк вата.
4) Мәдинә җырлый, Борис бии.

**4.** Сорауларга җавап бир.

1) Сабантуй нинди бәйрәм?
2) Ул кайчан була?
3) Сабантуйда нинди уеннар була?
4) Син Сабантуйга кем белән барасың?

**5.** Диалогларны укы һәм дустың белән сөйләш.

а) — Лилия, син Сабантуйга кем белән барасың?
— Әти, әни белән барам.
— Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?
— Бәйрәм  сәгать унда башлана.

ә) — Фәрит, мин Сабантуйда чүлмәк ваттым. Миңа бүләк бирделәр.
— Бик яхшы. Ә мин биедем.
— Сиңа бәйрәм ошадымы?
— Әйе, миңа бәйрәм ошады. Мин Сабантуйны яратам.

б) — Костя, син нинди бәйрәмнәр яратасың?
— Мин Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен яратам.
— Син Сабантуйга барасыңмы?
— Әйе, мин Сабантуйга барам.

6. Диалогка төшеп калган җөмләләрне куеп укы.

— Айдар, Сабантуй кайчан була?
— ... .
— ... ?
— Әйе, барам. Ә син барасыңмы?
— ... .

7. Заполни пустые клеточки и узнай, куда ходили дети.




**колын** — жеребёнок

8. Сабантуй турында сөйләргә өйрән.

# 87–88 нче дәресләр

**1.** Текстны укы.

Нәүрүз — язны каршылау бәйрәме. Нәүрүз яңа көн (ел) дигәнне аңлата. Нәүрүз бәйрәме — ул дуслык бәйрәме. Бәйрәмдә кешеләр тәмле ризыклар пешерәләр, кунакка йөриләр, җырлыйлар, бииләр, күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы — Нәүрүзбикә. Нәүрүз котлы булсын!

**каршылау** — встреча
**күңел ачалар** — веселятся
**хуҗа** — хозяин



**2.** Сорауларга җавап бир.

1) Нәүрүз нинди бәйрәм?
2) Бәйрәмнең хуҗасы кем?
3) Бәйрәмдә нишлиләр?

**3.** Кайсы раслау дөрес?

1) Нәүрүз — язгы бәйрәм.
Нәүрүз — кышкы бәйрәм.

2) Нәүрүз — гаилә бәйрәме.
Нәүрүз — дуслык бәйрәме.

3) Нәүрүз яңа ел дигәнне аңлата.
Нәүрүз иске ел дигәнне аңлата.

4) Бәйрәмнең хуҗасы — Кыш бабай.
Бәйрәмнең хуҗасы — Нәүрүзбикә.

**4.** Расскажи своему другу о том, что вчера у вас был праздник Навруз. На праздник пришла Наврузбике. Вы пели, танцевали, играли. Было очень весело.

**5.** Г. Гәрәеваның «Нәүрүз һәм балалар җыры»н өйрәнегез.

Яратыгыз җәйне дә,
Яратыгыз кышны да,
Яратыгыз көзне дә,
Яратыгыз язны да.
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!
Телисең изге теләк.
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!
Телисең изге теләк.

## 89–90 нчы дәресләр

**1.** Бу бәйрәм исемнәре кайсы рәсемнәргә туры килә? Раштуа, Масленица, Пасха, Яңа ел, Ураза бәйрәме.












**2.** Текстны укы.

Масленица бәйрәме — күңелле бәйрәм. Ул кыш көне була. Бәйрәмдә коймак пешерәләр, кунакка баралар, бииләр, җырлыйлар.

Бәйрәмнең символы — зур салам карачкы. Зурлар да, балалар да төрле уеннар уйныйлар, тауда чана, чаңгы шуалар, карачкы тирәли әйлән-бәйлән (хоровод) бииләр, язны чакыралар. Аннан соң карачкыны яндыралар.

**салам карачкы** — соломенное чучело
**яндыралар** — сжигают

**3.** Бу нинди уеннар?







**4.** Сорауларга җавап бир.

1) Масленица нинди бәйрәм?
2) Бәйрәмнең символы нәрсә?
3) Бәйрәмдә нишлиләр?

**5.** Төшеп калган җөмләләрне куеп, диалогны укы.

— Булат, әйдә бәйрәмгә барабыз.
— ... ?
— Масленица бәйрәме.
— Ә анда нишлиләр?
— ... .

**6.** Диалогларны укы һәм дустың белән сөйләш.

а) — Айрат, мин сине кунакка чакырам. Әби тәмле коймаклар пешерде.
— Рәхмәт, Саша. Бүген нинди бәйрәм?
— Бүген Масленица бәйрәме.

ә) — Фәридә, син кая барасың?
— Бәйрәмгә.
— Кем белән барасың?
— Дуслар белән барам.
— Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?
— Бәйрәм сәгать унда башлана.

## 91 нче дәрес

### Проверь себя!

**1.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нишли?







**2.** Спроси у друга:

— какие праздники ему нравятся;
— нравится ли ему праздник Пасхи;
— как дома празднуют этот праздник.

**3.** Диалогка төшеп калган җөмләләрне куеп укы.

— Айдар, син нинди бәйрәмнәр беләсең?
— ... .
— Сиңа нинди бәйрәм ошый?
— Миңа Масленица бәйрәме ошый. Коля, ә сиңа нинди бәйрәм ошый?
— ... .










# КЕЧКЕНӘ ДУСЛАРЫБЫЗ

## 92–94 нче дәресләр



**1.** Татарча әйт.

Ухо, глаза, нос, пасть, хвост, лапы.

**2.** Текстны укы.

Минем этем бар. Аның исеме Рекс. Рекс күп йөгерә, күп өрә, күп ишетә, күп күрә. Мин аны яратам. Мин эткә тәмле ашлар бирәм.

**3.** Составь и напиши вопросы к предложениям упражнения 2. Используя вопросы, поговорите друг с другом.

**4.** Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.

— ... ?

— Әйе, минем этем бар.

— Аның исеме ничек?

— ... .

— Ул нинди?

— ... .

— Ул нәрсә ярата?

— ... .

Мәхмүт Хөсәен «Безнең дуслары-быз»

**5. Исеңдә калдыр!**

**тәпиéн бирә́** — подаёт лапу

**каршы́ алá** — встречает

**комáндалар үти́** — выполняет команды

**6.** Посмотри на рисунки и скажи, какие повадки есть у собаки.



**7.** Прочитай текст, вставляя пропущенные окончания. Расскажи его содержание.

Минем эт… бар. Аның исем… — Акбай. Акбай өй… яши. Ул бик матур, акыллы. Ул тәпиен бир… , сумканы ал… , командалар үт(ә)… . Без аны бик яратабыз.

**8.** Шигырьне укы. Ошаса, ятла.

### Маэмай

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә.

Муса Җәлил

**9.** Допустим, у тебя тоже есть собака. Как ты ухаживаешь за ней? Напиши маленький рассказ и перескажи его соседу по парте.

**10.** Составь диалог по содержанию своего рассказа. Поговорите с соседом по парте.

**11.** Малайларның этләрен тап һәм токымнарын (порода) әйт.



## 95–97 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укы.

### Дуслар



Кәримнең эте бар. Аның исеме Актырнак. Кәрим аны бик ярата. Актырнак та Кәримне бик ярата. Бервакыт Актырнакның тәпиләре авырта башлады. Кәрим гел аның янында булды. Ул Актырнакка көн саен ипи, аш бирде. Актырнак терелде.

Бервакыт ул Кәрим белән бергә урамга чыкты. Менә ниндидер эт Кәримгә өрә башлады. Актырнак та эткә өрде. Янәсе (мол):

— Син минем хуҗама тимә. Ул минем дустым. Мин аны яратам һәм саклыйм.

Мәрьям Галләмовадан

**2.** Найди в тексте «Дуслар» предложения о том, что:

— у собаки болит лапа;
— Карим любит собаку;
— Карим ежедневно ухаживает за собакой;
— собака поправилась;
— Актырнак защищал своего хозяина.

**3.** Нокталар урынына **чөнки, шуңа күрә** сүзләрен куеп яз.

1) Актырнакның аяклары авырта, ... ул ашамады.
2) Актырнак Кәрим белән урамга чыкты, ... ул терелде.

3) Азат бүген мәктәпкә килмәде, ... аның башы авырта.

**4.** Нокталар урынына кушымчаларны куй, дәфтәреңә яз. Җөмләләргә сораулар куй.

1) Кәрим эт... ипи, аш бирде. 2) Актырнак малай... ярата. 3) Ул Кәрим белән урам... чыкты.

**5.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Аның эте бар, ләкин ... . 2) Ул Актырнакка аш бирә, шуңа күрә ... . 3) Кәрим Актырнакка көн саен ипи, аш бирде, шуңа күрә ... . 4) Актырнак Кәримне ярата, чөнки ... .

**6.** Сорауларга җавап яз.

1) Кемнең Актырнак исемле эте бар?
2) Кәрим Актырнакны ничек карый?
3) Дуслар кая чыктылар?
4) Ни өчен Актырнак Кәримне саклый?

**7.** Диалогларны сөйләшегез.



— Нәфис, мин урамга Джек белән чыгам. Син чыгасыңмы?
— Әйе, мин дә Акбай белән чыгам.
— Кайчан?
— Кич белән.



**8.** Бу бәяләмәләрнең (оценка) кайсы Кәримгә туры килә?

Ярдәмчел, эшчән, ялкау, акыллы, тырыш, начар, тәрбияле.

## 98–99 нчы дәресләр

**1.** Диалогларны укы. Дустың белән сөйләшегез.



— Синең песиең бармы?
— Бар.
— Синең песиең нинди төстә?
— Ул кара һәм ак төстә.
— Песиегез тычкан тотамы?
— Әйе, ул җәй көне бакчада тычкан тота.
— Син песиең белән уйныйсыңмы?
— Әйе, без бергә уйныйбыз.
— Синең песиеңнең күзләре нинди?
— Аның күзләре яшел.

**2.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Песиемнең муены ак төстә, шуңа күрә … . 2) Ул бик акыллы һәм хәйләкәр, шуңа күрә … . 3) Ул битен, тәпиләрен юа, шуңа күрә … . 4) Ул тиз йөгерә, шуңа күрә … .

**3.** Әйтик, синең песиең бар. Рәсемгә кара, хикәяне дәвам ит.

Минем песием бар. Аның исеме — Акмуен. Ул … .





**4.** Диалогны укы. Ләйләгә песине эзләргә булыш.

— Әнием, Акмуен кайда?
— Кайда икән (где же)? Юыну бүлмәсендәме?
— Юыну бүлмәсендә юк.
— Песи өстәл астындамы?
— Өстәл астында юк.
— Песи ишек артындамы?
— Ишек артында юк.
— Телевизор артындамы?
— Телевизор артында юк.
— Ә кайда соң Акмуен?
— ... .



## 100–101 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

**тәмле́** — вкусно
**тәмлерә́к** — вкуснее
**би́к тәмле́** — очень вкусно
**тәмле́ ту́гел** — не вкусно

**2.** Измени данные слова по образцу упражнения 1.

Матур, зур, кечкенә.

**3.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

Йорт [йӧрт], гел [гӗл], тәмле [тәмлә́], бәхәсләшәләр [бәхәсләшә́ләр], азык [а°зы́қ], тычкан [тычқа́н], сыек [сыйы́қ], орлык [ŏрлŏ́қ].

**4.** Әкиятне сәнгатьле укырга өйрән.

## Кем нәрсә ярата?



Бер йортта песи, эт, әтәч, кәҗә яшиләр. Кич белән алар гел бергә сөйләшәләр. Сөйләшәләр, сөйләшәләр дә бәхәсләшәләр икән. Кем нәрсә ярата? Нәрсә тәмлерәк?



— Песи, син нәрсә яратасың?

— Иң тәмле ризык — сөт, — ди песи. — Аннан соң бер тычкан ашыйсың, бик тәмле була.



— Әтәч, син нәрсә яратасың?

— Сөт бик сыек, ул тәмле түгел. Ә менә солы орлыгы тәмле, — ди әтәч.

— Юк, юк, — ди эт. — Орлык тәмле түгел. Менә сөяк тәмле була.



— Нәрсә сөйлисең син, — ди кәҗә. — Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә, — ди ул.

Алар бәхәсләшәләр, бәхәсләшәләр — һаман бәхәсләшәләр, ди.

Ә сез ничек уйлыйсыз: кем хаклы?

**бәхәсләшәләр** — спорят
**солы** — овёс
**сыек** — жидкий
**орлык** — зерно
**сөяк** — кость
**кем хаклы** — кто прав

Тыңла һәм укы!

**5.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Бер йортта песи, ... . 2) Алар гел ... . 3) Син нәрсә ... ? 4) Алар һаман ... , ди.

**6.** Бу җөмләләрне кем әйтә?

1) «Иң тәмле ризык — сөт», — ди ... .
2) «Сөт тәмле түгел», — ди ... .
3) «Орлык бик тәмле», — ди ... .
4) «Орлык тәмле түгел», — ди ... .
5) «Сөяк тәмле», — ди ... .

**7.** Сорауларга җавап бир.

1) Бер йортта кемнәр яшиләр?
2) Песи нәрсә ди?
3) Әтәч нәрсә ди?
4) Эт нәрсә ди?
5) Кәҗә нәрсә ди?

**8.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нәрсә ярата?



**9.** Әкиятне сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирергә онытмагыз.

## 102 нче дәрес

### Проверь себя!

**1.** Диалогны репликалар өстәп укы. Иптәшең белән сөйләш.



— Синең этең бармы?
— ... .
— Синең этең нинди?
— ... .
— Син аны ничек карыйсың?
— ... .
— Син эт белән урамда йөрисеңме?
— ... .



**2.** Муса Җәлилнең «Маэмай» шигырен яттан сөйлә.

**3.** Җөмләләргә сорау куй.

1) Мин песиемне бик яратам. 2) Песием дә мине бик ярата. 3) Ул бик акыллы һәм хәйләкәр. 4) Ул кара һәм ак төстә. 5) Аның аяклары көчле.

**4.** Как скажешь, что:

— Айрат каждый день гуляет с собакой, поэтому ему весело;
— у Айрата есть большая, красивая собака, а у Айнура собака маленькая;
— у тебя есть кошка, и она очень красивая;
— ты любишь кошек, но у тебя нет кошки?

**5.** Акмуен турында сөйлә.

**6.** Напиши маленький рассказ о любимом животном.

## Өстәмә уку өчен әсәрләр

### Көз һәм балалар җыры

— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдәниләр бар?
— Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.

— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә яңгырлар,
Җылы, суык көннәр бар.

— Көз, көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
— Кәрзинемдә сары, кызыл,
Алтын, матур төсләр бар.

Гөлсинә Гәрәева



## Яшел чыршы

Тышта буран бөтен җиргә карлар тутыра,
Безнең бүлмәдә ямь-яшел чыршы утыра.
Яшел чыршының очына йолдыз куелган.
Яңа елны каршыларга дуслар җыелган.
Бүген бәйрәм! Әйлән-бәйлән уйныйк-гөрләшик.
Бүген бәйрәм! Бәйләм-бәйләм бүләк өләшик.

Җәвад Тәрҗеманов



## Яз житә

Кояш көлеп карый безгә,
Күзләр чагыла.
Елгалардан бозлар ага
Диңгез ягына.

Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып, тып, тып итә
Эре-эре тамчылар.

Агачка кунып чыпчыклар
Чыелдашалар.
Яшькелт-кара сыерчыклар
Әй җырлашалар.

Тиздән шаулап яфрак ярыр
Озын ак каен,
Ал чәчәкләр алып килер
Безгә май ае.

Фатих Кәрим

## Җәйге болында

Кызыл, сары, зәңгәр, күк...
Бик күп төрле чәчәкләр
Сабантуйга җыелган.
Яңгыр үтте, җил тынды,
Күр салават күперен —
Бар да шуннан коелган:
Кызыл, сары, зәңгәр, күк...

Шәүкәт Галиев

**тынды** — здесь: утих
**салават күпере** — радуга
**коелган** — осыпались



# Сүзлек

## А

**абы́й** — старший брат, дядя

**ава́з** — звук

**авы́з** — рот

**авы́л** — деревня

**авы́р** — тяжело, тяжёлый; трудно, трудный

**авыртá** — болит

**авырыи́й** — болеет

**агá** — течёт

**ага́ч** — дерево

**агулы́** — ядовитый

**аз** — мало

**азы́к** — пища, корм

**ай** — месяц

**ак** — белый

**акбу́р** — мел

**акры́н** — медленно; медленный

**акчá** — деньги

**акыллы́** — умный

**алá** — берёт

**алдындá** — впереди

**алмá** — яблоко

**алмагáч** — яблоня

**алтáу** — шестеро

**алты́н** — золото; золотой

**алъяпкы́ч** — фартук

**андá** — там

**аннáн соң** — потом

**аны́** — его, её

**аны́ң** — его, её; у него, у неё

**аңá** — ему, ей; к нему, к ней

**аркылы́** — через

**арттá** — позади, сзади

**арыслáн** — лев

**ас** — низ

**ат** — лошадь

**ата́** — отец

**атна́** — неделя

**ача́** — открывает

**аш** — суп

**а́ша** — ешь

**аша** — через

**ашамлы́к** — продукт

**ашата́** — кормит

**а́ш-су** — кушанье

**ашы́й** — ест

**аю́** — медведь

**ая́з** — безоблачный

## Ә

**әбәклé уйны́й** — играет в пятнашки

**әдәплé** — вежливый

**әзерли́** — готовит

**әйбә́т** — хорошо; хороший

**әйбéр** — вещь

**әйé** — да

**әйтә́** — говорит

**әкия́т** — сказка

**әкрéн** — медленно; медленный

## Б

**база́р** — рынок

**бай** — богач; богатый

**бака́** — лягушка

**бакча́** — сад

**бакчачы́** — садовник

**бал** — мёд

**бала́** — ребёнок

**бала́н** — калина

**баллы́** — сладкий

**балта́** — топор

**балы́к** — рыба

**балыкчы́** — рыбак

**бар I** — есть

**бар II** — иди

**бара́** — идёт

**барма́к** — палец

**баса́** — встаёт

**баты́р** — герой, богатырь

**ба́у** — верёвка

**башкала́** — столица

**башлана́** — начинается

**башта́** — сначала, сперва

**бәби́** — младенец

**бәбкә́** — гусёнок; утёнок

**бәйрә́м** — праздник

**бәләкә́й** — маленький

**бәле́ш** — бэлиш

**бәрәңге́** — картофель

**бәхе́т** — счастье

**бәя́** — цена

**безгә́** — нам, к нам

**безне́** — нас

**безне́ң** — наш

**бер** — один

**бера́з** — немного

**бе́рвакыт** — однажды

**бергә́** — вместе, совместно

**бе́ркайчан** — никогда

**бе́ркем** — никто

**бе́рнинди** — никакой

**бетә́** — заканчивается, завершается

**бетергé́ч** — стёрка

**бетте́** — закончилось, завершилось

**бие́к** — высоко; высокий

**бии́** — пляшет, танцует

**бик** — очень, весьма

**бирә́** — даёт

**бире́м** — задание

**бит I** — лицо

**бит II** — страница

**биялә́й** — варежка, варежки

**боз** — лёд

**бозлавы́к** — гололедица

**болы́н** — луг

**болы́т** — туча

**борча́к** — горох

**борчылу́** — беспокойство

**боры́н** — нос

**боры́ч** — перец

**ботка́** — каша

**бөте́н** — весь, целый

**бу** — это

**буенча́** — по

**була́** — бывает

**булыша́** — помогает

**бүге́н** — сегодня

**бүлә́к итә** — дарит

**бүлмә́** — комната

**бүре́** — волк

**бүре́к** — шапка

## В

**вак** — мелкий

**вакы́т** — время

**вата́** — разбивает

**Вата́н** — Родина

## Г

**гае́п** — вина

**гафу́ ит(егез)** — извини(те)

**гомे́р** — жизнь

**гөл** — комнатный цветок

**гөлҗиме́ш** — шиповник

**гөмбә́** — гриб

## Д

**да (дә)** — тоже

**дару́** — лекарство

**дәре́с** — урок

**дәресле́к** — учебник

**ди** — говорит

**дөге́** — рис

**дуңгы́з** — свинья

**дус** — друг

**дуслы́к** — дружба

**дүшәмбе́** — понедельник

## Е

**егыла́** — падает

**ел** — год

**ела́н** — змея

**елга́** — река

**елмая́** — улыбается

**ел фасылы́** — время года

**елы́й** — плачет

**ера́к** — далеко

**еш** — часто

## Ж

**жанва́р** — зверь

**җәе́н, җә́й көне** — летом

**җәнле́к** — зверь

**җилә́к** — ягода

**җиме́ш** — плод

**җимле́к** — кормушка для птиц

**җиңе́л** — легко; лёгкий

**җир** — земля

**җитә́ I** — наступает

**җитә́ II** — достаточно

**җөмлә́** — предложение

**җыештыра́** — убирает, прибирает

**җылы́** — тепло; тёплый

**җылыта́** — греет

**җыр** — песня

**җырлы́й** — поёт

**җыя́** — собирает

## З

**зарарлы́** — вредный

**зәңгә́р** — синий, голубой

**зинһа́р** — пожалуйста

**зур** — большой

**зурла́р** — взрослые

## И

**игътиба́р** — внимание

**Иде́л** — Волга

**иҗе́к** — слог

**икә́н** — оказывается

**икә́ү** — вдвоём

**ил** — страна

**ине́ш** — ручей

**иң** — самый

**ипи́** — хлеб

**иптә́ш** — товарищ

**иртә́** — утро

**иртәгә́** — завтра

**иртә́н** — утром

**иртәнге́ аш** — завтрак

**иртәрә́к** — пораньше

**ис** — запах

**исә́** — дует

**и́скиткеч** — изумительный

**ит** — мясо

**итә́к** — юбка

**ите́к** — сапоги, сапог

**ишек** — дверь

# Й

**йоклы́й** — спит

**йокы́** — сон

**йомша́к** — мягкий

**йомырка́** — яйцо

**йорт** — дом

**йөгерә́** — бежит, бегает

**йөз** — сто

**йөзә́** — плывёт, плавает

# К

**каба́к** — тыква

**кабатлы́й** — повторяет

**кавы́н** — дыня

**кадерле́** — дорогой

**кадә́р** — до

**каз** — гусь

**ка́йбер** — некоторый

**ка́йда?** — где?

**каймак** — сметана

**кайна́р** — горячий

**ка́йсы?** — который?

**кайта́** — возвращается

**ка́йчан?** — когда?

**кайчы́** — ножницы

**кана́т** — крыло

**каплы́й** — покрывает, закрывает

**кар** — снег

**кара́** — чёрный

**карабода́й** — гречка

**карбы́з** — арбуз

**кара́ карга́** — грач

**карлыга́н** — смородина

**карлыга́ч** — ласточка

**карт** — старый; старик

**карчы́к** — старуха

**каршылы́й** — встречает

**каршында́** — перед

**карый́** — смотрит; ухаживает

**кат** — этаж

**кача́** — прячется

**кояшлы́** — солнечный

**кәбестә́** — капуста

**кәе́ф** — настроение

**кәҗә́** — коза

**кәрзи́н** — корзина

**кәшәкә́** — клюшка

**кебе́к** — как

**ке́мдер** — кто-то

**ке́мне?** — кого?

**ке́мнеке?** — чей?

**ке́мнең?** — кого? чей?

**керә́** — заходит, входит

**керергә́ мөмки́нме?** – можно войти?

**керпе́** — ёж

**кесә́л** — кисель

**кечкенә́** — маленький

**кеше́** — человек

**кибе́т** — магазин

**киенә́** — одевается

**кие́п карый́** – примеряет

**киля́** — приходит, идёт (сюда)

**килешә́** — идёт, подходит (об одежде)

**ки́нәт** — вдруг

**киң** — широкий

**киңә́ш** — совет

**кисә́** — режет

**китә́** — уходит

**кич** — вечер

**кичә́** — вчера

**ки́ч белән** — вечером

**кичке́ аш** — ужин

**кия́** — надевает

**коена́** — купается

**койры́к** — хвост

**кола́к** — ухо

**колы́н** — жеребёнок

**котла́у** — поздравление

**көз** — осень

**көймә́** — лодка

**көлә́** — смеётся

**көрә́к** — лопата

**көрәшә́** — борется

**көтә́** — ждёт

**көчле́** — сильный

**куе́** — густо; густой

**кул** — рука

**кулъяулы́к** — носовой платок

**курка́** — боится

**курка́к** — трусливый

**куя́** — ставит, кладёт

**куя́н** — заяц

**күбәлә́к** — бабочка

**күгәрче́н** — голубь

**күз** — глаз

**күл** — озеро

**күлмә́к** — платье, рубашка

**күнегү́** — упражнение

**күңелле́** — весело; весёлый

**күп** — много

**кү́пме?** — сколько?

**кыздыра́** — печёт (солнце)

**кызы́к** — интересно; интересный

**кыңгыра́у** — звонок

**кыр** — поле

**кыска́** — короткий

**кычытка́н** — крапива

**кы́ш көне, кышы́н** — зимой

**кыя́р** — огурец

# Л

**лалә́** — тюльпан

**лә́кин** — но, однако

# М

**май** — масло

**мактыи́й** — хвалит

**мату́р** — красиво; красивый

**мәка́ль** — пословица

**мәтрүшкә́** — душица

**ме́нә** — вот

**менә́** — поднимается

**мең** — тысяча

**миләш** — рябина

**милләт** — нация

**милли́** — национальный

**мине́** — меня

**минеке́** — мой

**мине́м** — мой, у меня

**миңа́** — мне

**мич** — печь

**монда́** — здесь

**мөмки́н** — можно

**муе́н** — шея

# Н

**нача́р** — плохой

**нәрсәгә?** — чему?

**нәрсәнең?** — чего?

**нечкә́** — тонкий

**ни?** — что?

**ни́гә?** — зачем?

**ни́чек?** — как?

**ни́ өчен?** — почему?

**ни́шләде?** — что сделал?

**нишлә́мәде?** — что не сделал?

**ни́шли?** — что делает?

**нокта́** — точка

# О

**оекба́ш** — носок, носки

**оза́к** — долго

**озы́н** — длинный

**он** — мука

**оны́к** — внук, внучка

**оныта́** — забывает

**оча́** — летит

**очрашу́** — встреча

**очучы́** — лётчик

**ошы́й** — нравится

**оя́** — гнездо

## Ө

**өй** — дом

**өйрәнә́** — учится

**өрә́** — лает

**өстә́л** — стол

**өсте́** — поверхность

**өстендә́** — на поверхности

**өте́р** — запятая

**өчен** — для

## П

**пәрәмә́ч** — перемяч

**песи́** — кошка

**песнә́к** — синица

**печә́н** — сено

**пешерә́** — варит

**പешт**

**пилмә́н** — пельмени

**пөхтә́** — аккуратно; аккуратный

**пыла́у** — плов

**пыча́к** — нож

**пычкы́** — пила

**пычра́к** — грязно; грязный

**пыяла́** — стекло; стеклянный

## Р

**рәсе́м** — рисунок

**рәсе́м ясы́й** — рисует

**рәхә́т** — приятно, отрадно

**рәхи́м ит(егез)!** — добро пожаловать!

**рәхмә́т** — спасибо

**ризá** — согласен, согласна

**рөхсә́т** — разрешение

**ру́сча** — по-русски

# С

**сабы́н** — мыло

**савы́т-саба** — посуда

**саéн** — каждый

**саескáн** — сорока

**сай** — мелко; мелкий

**сайлы́й** — выбирает

**саклы́й** — охраняет, бережёт

**салá** — кладёт; снимает

**салкы́н** — холодно; холодный

**сан** — число

**санамы́ш** — считалка

**сандугáч** — соловей

**саны́й** — считает

**сарáн** — скупой

**сары́** — жёлтый

**сары́к** — овца

**сарымсáк** — чеснок

**сатá** — продаёт

**сатучы́** — продавец, продавщица

**сат́ып алá** — покупает

**сәламәтлéк** — здоровье

**сезгә́** — вам, к вам

**сезнé** — вас

**сезнéң** — ваш

**сеңéл** — младшая сестра

**сибә́** — поливает

**синé** — тебя

**синéң** — твой, у тебя

**сиңá** — тебе

**соң I** — поздно

**соң II** — после

**сөйли́** — рассказывает

**сөртә́** — вытирает

**сөт** — молоко

**су** — вода

**суга́н** — лук

**сузы́к ава́з** — гласный звук

**сые́р** — корова

**сыерчы́к** — скворец

**сызлы́й** — болит

**сызыклы́** — в линейку

**сыйны́ф җитәкчесе́** – классный руководитель

# Т

**таба́ (өйгә́ таба́)** — по направлению (к дому)

**табига́ть** — природа

**табы́н** — накрытый стол

**табышма́к** — загадка

**тавы́к** — курица

**такта́** — доска

**тама́** — капает

**тама́к** — горло

**тамчы́** — капля

**тамы́р** — корень

**тара́к** — расчёска

**тарата́** — раздаёт, разбрасывает

**тари́х** — история

**тарты́к ава́з** — согласный звук

**тату́** — дружно

**та́у** — гора

**таш** — камень

**тәлинкә́** — тарелка

**тәмле́** — вкусно; вкусный

**тәнәфе́с** — перемена

**тәрбияле́** — воспитанный

**тәрти́п** — порядок

**тегүче́** — портной

**тел** — язык

**тели́м** — желаю

**теш** — зуб

**тиз** — быстро

**тиздә́н** — скоро

**тимерая́к** — коньки

**тоз** — соль

**тозлы́** — солёный

**токма́ч** — лапша

**тора́ I** — встаёт, стоит

**тора́ II** — живёт

**тота́** — ловит

**төзәтә́** — исправляет

**төлке́** — лиса

**төн** — ночь

**төрле́** — разный

**төс** — цвет

**төсле́** — цветной

**төшә́** — спускается

**туга́н** — родной

**туга́н көн** — день рождения

**туза́н** — пыль

**тук** — сыто; сытый

**тукра́н** — дятел

**тукталы́ш** — остановка

**туңа́** — замерзает, мёрзнет

**туп** — мяч

**түбәтә́й** — тюбетейка

**түгәрә́к** — круглый

**түли́** — платит

**тыңлы́й** — слушает

**тырыш** — старательный

## У

**уе́н** — игра

**уенчы́к** — игрушка

**уз** — проходи, входи

**укыта́** — учит

**урма́н** — лес

**урнашка́н** — находится

**урындык** — стул

**уса́л** — злой

**ут** — свет, огонь

**утыра́** — сидит

**уяна́** — просыпается

## Ү

**үбә́** — целует

**үзе́** — сам (сама, само)

**үлә́** — умирает

**үлә́н** — трава

**үрдә́к** — утка

**үсә́** — растёт

**үстерә́** — выращивает

**үтә́** — проходит

**үтерде́** — убил

## Ф

**файда́** — польза

**файдалы́** — полезно; полезный

**фил** — слон

## Х

**хайва́н** — животное

**халы́к** — народ

**хат** — письмо

**хата́** — ошибка

**хәерле́ көн!** — добрый день!

**хә́зер** — сейчас

**хәре́ф** — буква

**хикәя́** — рассказ

**хөрмәтле́** — уважаемый

**хуҗа́** — хозяин

**ху́ш килә́сез!** — добро пожаловать!

## Һ

**һәйкә́л** — памятник

**һәм** — и

**һәр** — каждый

**һә́ркем** — каждый (человек)

## Ч

**чакыра́** — зовёт, приглашает

**чакыру́** — приглашение

**чалба́р** — брюки

**чәкчә́к** — чак-чак

**чәнечке́** — вилка

**чәч** — волос

**чәчә́** — сеет

**чәчә́к** — цветок

**чәчә́к ата́** — цветёт

**чебе́н** — муха

**чеби́** — цыплёнок

**чикләве́к** — орех

**чирә́м** — трава

**чиста́** — чисто; чистый

**чисталы́к** — чистота

**чия́** — вишня

**чөгендéр** — свёкла

**чө́нки** — потому что

**чүлмә́к** — горшок

**чүпрә́к** — тряпка

**чыга́** — выходит

**чык** — выйди

**чыная́к** — чашка

**чыпчы́к** — воробей

**чыршы́** — ель

# Ш

**шагы́йрь** — поэт

**шакмаклы́** — в клетку

**шалка́н** — репа

**шалтырата́** — звони́т

**шалтыры́й** — звенит

**шат** — рад

**шатлана́** — радуется

**шая́н** — весёлый

**шәһә́р** — город

**шигы́рь** — стихотворение

**шикә́р** — сахар

**шимбә́** — суббота

**шуа́** — катается

**шугала́к** — каток

**шул** — тот

**шуңа́ күрә** — поэтому

**шушы́** — это

# Э

**эзли́** — ищет

**элә́** — вешает

**элге́ч** — вешалка

**эле́к** — давно

**эне́** — младший брат

**эри́** — тает

**эссе́** — жарко; жаркий

**эт** — собака

**эчә́** — пьёт

**эчәсе́ килә́** — хочется пить

**эчендә́** — внутри

**эш** — работа

**эшли́** — работает

**эшче́** — рабочий

# Ю

**ю** — мой

**юа́** — моет

**югалта́** — теряет

**юк** — нет

**юл** — дорога

**юма́рт** — щедрый

**юына́** — умывается

# Я

**ява́** — идёт (снег, дождь)

**явы́з** — злой

**яз** — весна

**яза́** — пишет

**я́з көне, язы́н** — весной

**як (туга́н як)** — сторона (родная сторона)

**якты́** — светлый

**якы́н** — близко; близкий

**я́к-якка** — по сторонам

**ялгы́ш** — ошибочно

**я́л итә** — отдыхает

**ялка́у** — ленивый

**я́л көне** — выходной

**я́ме** — ладно

**ямьле́** — прекрасно; прекрасный

**ямьсе́з** — некрасивый

**яна́** — горит

**янында́** — возле, около

**яңа́** — новый

**яңгы́р** — дождь

**яр** — берег

**яра́мый** — нельзя

**яратá** — любит

**ярдə́м** — помощь

**ярмá** — крупа

**ярьíш** — соревнование

**ясьíй** — делает, рисует

**ятá** — лежит

**ятльíй** — учит наизусть

**яульíк** — платок

**яфрáк** — лист

**яфрáк ярá** — распускает листья

**яхшьí** — хорошо; хороший

**яшéл** — зелёный

**яшелчə́** — овощ

**яшú** — живёт

# Эчтәлек

**Мәктәптә**

4–5 нче дәресләр ........ 7
8–9 нчы дәресләр ........ 11
10–11 нче дәресләр ........ 14
12–13 нче дәресләр ........ 17
14–16 нчы дәресләр ........ 19
17–19 нчы дәресләр ........ 21
20–21 нче дәресләр ........ 23
22–24 нче дәресләр ........ 25
25–27 нче дәресләр ........ 28
28 нче дәрес ........ 31

**Көндәлек режим**

29–31 нче дәресләр ........ 33
32–33 нче дәресләр ........ 35
34 нче дәрес ........ 37

**Ашханәдә**

35–37 нче дәресләр ........ 38
38–39 нчы дәресләр ........ 41
40 нчы дәрес ........ 44

**Без әти-әниләргә булышабыз**

41–42 нче дәресләр ........ 45
43–45 нче дәресләр ........ 47
46–47 нче дәресләр ........ 51
48 нче дәрес ........ 52

**Туган көн — күңелле бәйрәм**
49–50 нче дәресләр ........................ 54
51–54 нче дәресләр ........................ 57
55 нче дәрес ........................ 60

**Яраткан уеннарым**
56–58 нче дәресләр ........................ 61
59–61 нче дәресләр ........................ 65
62–64 нче дәресләр ........................ 67
65 нче дәрес ........................ 69

**Шәһәрдә һәм авылда**
66–68 нче дәресләр ........................ 71
69–71 нче дәресләр ........................ 73
72–74 нче дәресләр ........................ 75
75–77 нче дәресләр ........................ 77
78–80 нче дәресләр ........................ 79
81 нче дәрес ........................ 81

**Милли бәйрәмнәр**
82–83 нче дәресләр ........................ 83
84–86 нчы дәресләр ........................ 85
87–88 нче дәресләр ........................ 88
89–90 нчы дәресләр ........................ 90
91 нче дәрес ........................ 92

**Кечкенә дусларыбыз**
92–94 нче дәресләр ........ 94
95–97 нче дәресләр ........ 97
98–99 нчы дәресләр ........ 99
100–101 нче дәресләр ........ 100

**Өстәмә уку өчен әсәрләр** ........ 104

**Сүзлек** ........ 107

Учебное издание

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна
**Гиниятуллина** Лейсан Адиповна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**3 класс**

Учебник для образовательных организаций начального общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова,*
*Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина*
Продюсер проекта *А.М. Ганиев*
Руководитель проекта *А.Т. Низамеева*
Художественный руководитель *С.В. Киатров*
Вёрстка *Д.И. Бариев*
Технический руководитель *И.М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф.Ш. Ахметзянова, Г.М. Ахметзянова, И.А. Закиев*
Художники *А.Р. Ромашова, Н.К. Авдеева*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 2.09.2025. Формат 84х108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 7. Тираж 8 000 экз. Заказ № 29027.

Издательство «Татармультфильм».
420034, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в соответствии с предоставленными материалами в типографии
ООО «ЛД-ПРИНТ»
196643, Россия, Санкт-Петербург, Колпинский р-н, пос. Сапёрный,
ш. Петрозаводское, д. 6, стр. 6. Тел. (812) 462-83-83,
e-mail: office@ldprint.ru


аквапарк



ФГОС

**Школьный учебник**



Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

ТАТАР ТЕЛЕ

3

9 785906 508607

издательство
«Татармультфильм»